Правовые положения, устанавливающие требование о том, что для постановки граждан на учет в качестве нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования необходимо предоставить выписку из домовой книги, а также последствия непредоставления такой выписки — отказ в постановке на соответствующий учет, в оспариваемом Административном регламенте не содержатся. Данное требование установлено в Административном регламенте предоставления муниципальной услуги по принятию на учет граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, в городе Казани, утвержденном постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 13 ноября 2018 года № 5805, конституционность которого гражданином И.А. Макаровым не оспаривается, а потому не может быть оценена в рамках настоящего дела, рассматриваемого Конституционным судом Республики Татарстан в порядке конкретного нормоконтроля.

Таким образом, оспариваемые положения пунктов 2.5 и 2.8 Административного регламента предоставления муниципальной услуги по выдаче справки (выписки) в их взаимосвязи с абзацем третьим пункта 1 приложения № 1 к данному Административному регламенту, утвержденному постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 21 ноября 2013 года № 10100 (в редакции постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 28 октября 2016 года № 4439), в той мере, в которой они для предоставления муниципальной услуги по выдаче справки (выписки) из домовой книги возлагали на заявителя обязанность по представлению домовой книги, не могут рассматриваться как отменяющие, ограничивающие или иным образом нарушающие конституционные права и свободы человека и гражданина, в том числе гражданина И.А. Макарова, и тем самым не противоречат статьям 13, 24 (часть вторая), 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 30, 54 (часть первая), 55 и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 6, частью второй статьи 46, частями первой и второй статьи 66, частями первой, второй и шестой статьи 67, статьями 68, 69, 71, 73 и пунктом 1 части первой статьи 104 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**постановил:**

1. Признать подпункт «а» пункта 5 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 5 декабря 2015 года № 100-ЗРТ «О внесении изменений в Закон Республики Татарстан “Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан”», в соответствии

с которым в пункте 1 статьи 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан» слова «нуждающимися в жилых помещениях» были заменены словами «в установленном порядке нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования», соответствующим Конституции Республики Татарстан.

2. Признать положения пунктов 2.5 и 2.8 Административного регламента предоставления муниципальной услуги по выдаче справки (выписки), в их взаимосвязи с абзацем третьим пункта 1 приложения № 1 к данному Административному регламенту, утвержденному постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 21 ноября 2013 года № 10100 (в редакции постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 28 октября 2016 года № 4439), в той мере, в которой они для предоставления муниципальной услуги по выдаче справки (выписки) из домовой книги возлагали на заявителя обязанность по представлению домовой книги, соответствующими Конституции Республики Татарстан.

3. Прекратить производство по настоящему делу в части, касающейся проверки конституционности положений пунктов 2.5 и 2.8 Административного регламента предоставления муниципальной услуги по выдаче справки (выписки) в их взаимосвязи с абзацем четвертым пункта 1 приложения № 1 к данному Административному регламенту, утвержденному постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 21 ноября 2013 года № 10100 (в редакции постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 28 октября 2016 года № 4439).

4. Настоящее Постановление окончательно, не подлежит обжалованию, вступает в силу немедленно после его провозглашения, действует непосредственно и не требует подтверждения другими органами и должностными лицами.

5. Настоящее Постановление подлежит незамедлительному опубликованию в газетах «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU). Постановление должно быть опубликовано также в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 88-П

Конституционный суд
Республики Татарстан

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИСЕМЕ БЕЛӘН

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**гражданин И.А. Макаров шикаятенә бәйле рәвештә «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасының, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацлары белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктларының аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

2020 ел
14 февраль
Казан шәһәре

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасының, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацлары белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктларының аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин И.А. Макаров шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья А.Р. Шакараев мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган орган-

нар вәкилләре — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең социаль законнар бүлеге мөдире Д.И. Мәхмүтов, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аппараты Хокук идарәсенең торак законнары мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары — Э.Я. Тимерханова аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең ярлыкау мәсьәләләре буенча секторы мөдире Д.А. Рослов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең социаль законнар бүлеге баш киңәшчесе А.А. Адыева, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминский, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге баш белгече Э.И. Гафиятуллина, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинова чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин И.А. Макаров «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасының, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацлары белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктларының аерым нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының

1 статьясындагы 5 пунктының «а» пунктчасы белән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясының 1 пунктында «торак урыннарга мохтаҗ дип» сүзләре «билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип» сүзләренә алмаштырылган.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пунктының нигезләмәләре (алга таба шулай ук — Административ регламент), муниципаль хезмәт, шулай ук муниципаль хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлегенә әлеге регламентка 1 нче кушымта нигезендә документларны (төп нөсхәләрне) кертәләр.

Административ регламентның 2.8 пунктының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез итеп тәкъдим ителгән документларның каралучы регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәвен карый.

Гражданин И.А. Макаров шикаять белдерә торган Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пункты нигезләмәләре буенча, йорт кенәгәсеннән өземтә бирү өчен, шул исәптән йорт кенәгәсе һәм шәхси торак йортка хокуклар турында документ (хокукны дәүләт теркәве турында таныклык яки шәхси торак йортның техник (кадастр) паспорты, яки Ростехинвентаризациянең — Федераль техник инвентаризацияләү бюросының Татарстан Республикасы филиалыннан хокук ияләре турында белешмә) кирәк.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүче — Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 29 ноябрендәге 987н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлегенә кергән авыр хроник авырудан интегүче инвалид. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ буларак исәпкә кую максатында гражданин И.А. Макаров, гаризага «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законы белән билгеләнгән документлар исемлеге һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 7 июнендәге 432 номерлы карары белән расланган Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 2.2 пункты нигезендә каралган документларны кушып, Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясенә (алга таба шулай ук — Администрация) гариза белән мөрәҗәгать иткән. Әмма Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы күрсәтмәсе нигезендә мөрәҗәгать итүчегә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ буларак исәпкә куюдан баш тартылган, чөнки әлеге күрсәтмәдән өземтәдә күрсәтелгәнчә, гражданин И.А. Макаров аз керемле дип танылырга мөмкин һәм аның тарафыннан йорт кенәгәсеннән өземтә, йортка техник паспорт (күчермә) бирелмәгән.

Мөрәҗәгать итүче, «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителгәнчегә кадәр (алга таба шулай ук — 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) торак урыны алу өчен торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирү юлы белән торак шартларын яхшырту хокукына Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче барлык инвалидлар, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче инвалид балалары булган, торак урыннарына мохтаҗлар дип танылган һәм 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан гаиләләр ия булган иде дип күрсәтә. Аның фикеренчә, 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре белән кертелгән үзгәрешләр, тигезлек һәм гаделлек, социаль дәүләтнең конституциячел принципларына карамастан, инвалидларның аеруча мохтаҗ булган өлешен — аз керемлеләрне, аларга бирелгән торак субсидиясен алу хокукыннан, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куюның законнар белән билгеләнгән шартларына туры килмәү сәбәпле, мәхрүм иткәннәр.

Гражданин И.А. Макаровка тиешле исәпкә куюдан шул исәптән йорт кенәгәсеннән өземтә бирелмәү нигезендә баш тартылганлыктан, аны бирү турындагы гариза белән ул Администрациягә мөрәҗәгать иткән. Ләкин Администрация, дәгъва белдерелә торган Административ регламент нигезендә өземтә алу өчен шул исәптән йорт кенәгәсе һәм шәхси торак йортка

хокуклар турында документ (хокукны дәүләт теркәве турында таныклык яки шәхси торак йортның техник (кадастр) паспорты, яки Ростехинвентаризациянең — Федераль техник инвентаризацияләү бюросының Татарстан Республикасы филиалыннан хокук ияләре турында белешмә) тапшырырга кирәк дип билгеләп, аңа йорт кенәгәсеннән өземтә бирүдән баш тарткан.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы 3 өлеше һәм Тәртипнең 2.4 пункты нигезендә, йорт кенәгәсеннән өземтә һәм йортка техник паспорт җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт органнарыннан, башка җирле үзидарә органнарыннан яисә аларга буйсынган оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып алына торган документларга кертелгәннәр һәм шунлыктан мөрәҗәгать итүчедән таләп ителә алмыйлар.

Шуңа бәйле рәвештә гражданин И.А. Макаров социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ буларак исәпкә куюдан йорт кенәгәсеннән өземтә бирелмәү нигезендә баш тарту законсыз булып тора һәм хокук нормалары белән бәйләнмәгән дип саный.

Моннан тыш, аның фикеренчә, аның тарафыннан дәгъва белдерелә торган Административ регламентның хокукый нигезләмәләре белән йорт кенәгәсен һәм шәхси торак йортка хокуклар турындагы документны мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә тиешле документларга кертү шулай ук законсыз һәм җирле үзидарә органнары карарларының һәм гамәлләренең законлы характеры турында конституциячел норма белән килешмәүче булып тора.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин И.А. Макаров Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасын, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацлары белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктларының аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 30, 54 (беренче өлеш), 55 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булды-

руга юнәлтелгән социаль дәүләт; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, урындагы затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә бурычлы; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең яки аларга өстенлекләрен билгеләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела; гражданнар шәхси, сәяси, социаль-икътисадый һәм мәдәни хокукларның һәм ирекләрнең бөтен тулылыгына ия; һәркемгә авырган, гарипләнгән һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; һәркем торакка хокуклы, беркем дә торагыннан нигезсез мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгаручы яисә киметүче законнар чыгарылмаска тиеш.

1.1. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, конституциячеллеге дәгъваланучы акт юкка чыгарылган булса яисә эшне карый башлаганчы йә аны карау чорында үз көчен югалткан булса, Татарстан Республикасы Конституция суды башлаган эш туктатылырга мөмкин, моңа бу актның гамәлдә булуы аркасында гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылган очраклар керми.

Суд утырышында эшне карый башлаганчы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 30 декабрендәге 4714 номерлы карары белән дәгъва белдерелә торган карарга үзгәрешләр кертелгән, алар нигезендә Административ регламентка 1 нче кушымта яңа редакциядә бәян ителгән. Кертелгән үзгәрешләр эчтәлегеннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган Административ регламентка 1 нче кушымтадагы 1 пунктының дүртенче абзацындагы шәхси торак йортка хокуклар турындагы документ (хокукны дәүләт теркәве турында таныклык яки шәхси торак йортның техник (кадастр) паспорты, яки Ростехинвентаризациянең — Федераль техник инвентаризацияләү бюросының Татарстан Республикасы филиалыннан хокук ияләре турында белешмә) бирү бурычына кагылышлы нигезләмә төшереп калдырылган. Димәк, әлеге эш буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктлары нигез-

ләмәләренең конституциячеллеген тикшерү өлешендә эш туктатылырга тиеш.

Шуның белән бергә, кертелгән үзгәрешләр эчтәлегеннән шулай ук күренгәнчә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан йорт кенәгәсен бирү бурычларына кагылышлы нигезләмә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2019 елның 30 декабрендәге 4714 номерлы карары редакциясендә) расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымтаның беренче өлешендәге 3 пунктында фактта сакланып калган һәм чагылыш тапкан. Күрсәтелгән нормалар аның торакка конституциячел хокукын бозуга хокукый нигез булып торган дип санаган мөрәҗәгать итүче позициясен исәпкә алып, Административ регламентның карала торган нормаларына үзгәрешләр кертү алар белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчегә йорт кенәгәсен бирү бурычын йөкләгән дәрәҗәдә дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерүгә каршы килә алмый.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану гамәлиятендәге мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар:

— «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасы, аның нигезендә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пунктында «торак урыннарга мохтаҗ дип» сүзләре «билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип» сүзләренә алмаштырылган;

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче ку-

шымтаның 1 пунктындагы өченче абзацы белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктлары нигезләмәләре, алар йорт кенәгәсеннән белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчегә йорт кенәгәсен бирү бурычын йөкләгән дәрәҗәдә.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының хокукый нигезләмәләре социаль яклау һәм торак законнары өлкәсенә кагылалар. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, икенче һәм бишенче өлешләр).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча әлеге органнар тарафыннан Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары хисабына (федераль бюджеттан бирелгән субвенцияләрдән тыш) мөстәкыйль гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләренә гражданнарның аерым категорияләренә, шул исәптән инвалидларга, социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен хәл итү керә (2 пунктның 24 пунктчасы); әлеге мәсьәләләр буенча федераль законнарда күрсәтелгән хокукны билгели торган нигезләмәләр булу-булмауга бәйсез рәвештә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары законнар, башка норматив хокукый актлар кабул итәргә хокуклы (3.1 пункт).

Аталган Федераль законның 26.3-1 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел.

Шулай итеп, 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы үзенә федераль законнар нигезендә карый торган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 (икенче өлеш) һәм 75 (2 пункт) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган.

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы нигезендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне норматив хокукый җайга салу әлеге Федераль закон, башка федераль законнар белән, алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Күрсәтелгән Федераль законның 12 (1 өлеш) һәм 13 (15 өлеш) статьялары белән үзара бәйләнештә 6 статьясы нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар административ регламентлар нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтергә тиеш; муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе җирле администрация тарафыннан билгеләнә.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенең 1.8 пункты нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә административ регламентлар билгеләнгән тәртиптә Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый акты белән расланалар.

Шулай итеп, Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслап, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзенә федераль законнар нигезендә бирелгән, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтләрне дөрес гамәлгә ашырган.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркемгә, шул исәптән авырган, гарипләнгән очракта һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш); һәркем торакка хокуклы; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья) дип билгели. Мәгънәсе буенча шундый ук гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7, 39 (1 өлеш), 40 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында билгеләнгән.

Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә, Россия, сәясәте кеше өчен лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итәрлек шартлар тудыруга юнәлдерелгән социаль дәүләт буларак (7 статья, 1 өлеш), һәркемнең торакка хокукын гамәлгә ашыруны гарантияли (40 статья, 1 өлеш), ул, лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук элементы буларак, халыкара җәмәгатьчелек тарафыннан танылган (Кеше хокуклары гомуми декларациясенең 25 статьясы һәм Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турында халыкара пактның 11 статьясы). Шуннан чыгып, Россия Федерациясе Конституциясе, һәркемнең торакка хокукын игълан итеп, әлеге хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру буенча дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының үзара бәйләнешле булу бурычын беркетә (40 статья, 2 өлеш), бер үк вакытта аны гамәлгә ашыру гарантиясе булып тора (2016 елның 12 апрелендәге 10-П номерлы Карар).

3.1. Бюджетларның мөстәкыйльлеге принцибы нигезендә (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 31 статьясы), Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләгәнчә, Россия Федерациясе субъектының бюджеты акчаларын тоту формалары һәм юнәлешләре (финанс белән тәэмин ителеше башка дәрәҗәләрдәге бюджетлардан субсидияләр һәм субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнардан тыш) Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә, ләкин шул ук вакытта алар хокуклы гына түгел, шулай ук үз бюджетларының баланслылыгын һәм бюджет акчаларын куллануның нәтиҗәлелеген мөстәкыйль тәэмин итәргә дә тиешләр (2018 елның 27 мартындагы 13-П номерлы Карар).

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясында билгеләнгән хокукый җайга салу максатчан характерга ия, аның билгеләнеше тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган аерым категорияләрдәге гражданнарның матди иминлеген тәэмин итү булып тора һәм гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чарасыннан гыйбарәт, аны билгеләү Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы булып тора дип Татарстан Республикасы Конституция суды берничә тапкыр күрсәткән иде инде. Бу исә аны бирү нигезләре һәм шартлары, социаль-икътисадый үсешнең әлеге этабында булган финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата (2016 елның 8 июлендәге 12-О номерлы, 2017 елның 12 июлендәге 32-О номерлы һәм башка билгеләмәләр).

Торак шартларын яхшыртуга торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) (алга таба шулай ук — торак субсидиясе) бирү рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чарасы «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан

Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пункты белән кертелгән. Башта Татарстан Республикасы закон чыгаручысы Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче инвалидлар һәм әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче инвалид балалары булган (алга таба шулай ук — инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр), торак урыннарына мохтаҗлар дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан гаиләләр өчен торак субсидиясен бирүне күздә тоткан.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, аны алу хокукына билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип танылган инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр ия булуын күздә тотып, торак субсидиясе бирү шартларын үзгәрткән. Россия Федерациясе Торак кодексының социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелү шартларын регламентлый торган 91.3 статьясының 1 өлеше нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә, бу торак урыннарына мохтаҗлар дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр саныннан аз керемлеләр дип танылган яки танылырга нигезе булганнар, шулай ук аларның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзалары кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә билгеләнә торган максималь күләмнән артып китүчеләр төшереп калдырылганны аңлата.

Торак урыннарына мохтаҗлар дип танылган яисә танылырга нигезләре булган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан торак урыннарына мохтаҗ инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр өчен хокукый җайга салуны үзгәрткәндә, Татарстан Республикасы закон чыгаручысы, Татарстан Республикасы бюджетының булган мөмкинлекләреннән чыгып, күрсәтелгән категориядәге затлар өчен федераль закон чыгаручы тарафыннан торак шартларын яхшырту механизмы инде каралган булуын кулланган.

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты, 49 статьясындагы 2 өлеше һәм 57 статьясындагы 2 өлеше 3 пунктының үзара бәйләнешле нигезләмәләре эчтәлегеннән күренгәнчә, әлеге Кодексның 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче гражданнар, аларны аз керемлеләр дип таныган һәм торак законнарында каралган тәртиптә алар тарафыннан торак урынына мохтаҗлыгы расланган очракта, социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары чираттан тыш бирелү хокукына ия.

Россия Федерациясе Конституция Суды 2019 елның 10 декабрендәге 39-П номерлы Карарында, социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә һәм торак урынына объектив мохтаҗлыкны раслауга карата торак законнарының гомуми таләпләрен үтәү шарты белән (әлеге Кодексның 49 статьясындагы 2 өлеше һәм 52 статьясындагы 1 өлеше), федераль закон чыгаручы гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль наем шартнамәләре буенча чираттан тыш, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче гражданнар өчен торак урыннары бирү мөмкинлеген билгеләгән (әлеге Кодексның 57 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты), дип күрсәтеп киткән.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды, аз керемлеләр дип танылган инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр аларга муниципаль торак фондыннан торак урыны бирү юлы белән торак шартларын яхшыртуга хокуклы, ә аз керемлеләр дип танылмаган шундый ук затлар категориясендәге гражданнар мондый хокукка ия түгел, дәгъва белдерелә торган хокукый җайга салуны кертү хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче һәм билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган иң күп сандагы инвалидларга дәүләт ярдәме күрсәтүне, бюджет акчалары хисабына үзенең хокукый табигате буенча охшаш социаль ярдәм чараларын берничә тапкыр алуны булдырмауны максат итеп куя һәм үзеннән-үзе конституциячел әһәмиятле максатны — аңа аеруча мохтаҗ гражданнарның торакка хокукын тәэмин итүне күздә тота дигән нәтиҗәгә килә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының карала торган җайга салуны үзгәртүдә мондый алымы Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позицияләренә җавап бирә, ул берничә тапкыр күрсәткәнчә, гаделлек, тигезлек һәм ярашканлык конституциячел принципларыннан закон чыгаручыга юнәлтелгән бер үк категориягә караган затларның хокукый хәлендә объектив һәм акылга ярашлы акланууга ия булмаган аерымлыклар кертүне тыю (бер үк яисә охшаш вәзгыятьләрдә торучы затлар белән төрлечә эш итүне тыю) килеп чыга; хокукый җайга салуның теге яки бу өлкәсендә гражданнарның хокукларындагы аермаларга китерә торган теләсә нинди дифференциация Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 17 (3 өлеш), 19 (1 һәм 2 өлешләр) һәм 55 (3 өлеш) статьялары таләпләренә җавап бирергә тиеш, әгәр аермалар бары тик объектив акланган, нигезләнгән һәм конституциячел әһәмиятле максатларга туры килсә генә рөхсәт ителә, ә әлеге максатларга ирешү өчен файдаланыла торган хокукый чаралар шуларга тиң (2001 елның 24 маендагы 8-П номерлы, 2007 елның 5 апрелендәге 5-П номерлы, 2010 елның 3 февралендәге 3-П номерлы, 2012 елның 27 февралендәге 3-П номерлы, 2019 елның 22 мартындагы 15-П номерлы һәм башка карарлар).

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Конституция

суды мондый дифференциациянең аз керемлеләр дип танылган, шулай ук андый дип танылмаган инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр мәнфәгатьләре балансын үтәгәндә генә акланырга мөмкин булуына игътибар итә, бу исә дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан натуралата торак урынын чиратсыз бирү яки торак субсидиясен түләү буенча закон нигезендә билгеләнгән бурычларын реаль үтәүне, димәк, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның санын исәпкә алып, тиешле бюджет планлаштыруын таләп итә.

Шулай итеп, «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасы, аның нигезендә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пунктында «торак урыннарга мохтаҗ дип» сүзләре «билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип» сүзләренә алмаштырылган, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

3.2. Дәгъва белдерелә торган закон нормасын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танып, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк дип саный. Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысына гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын билгеләү һәм юкка чыгару вәкаләте бирү ул чикләнмәгән ирекле эш итә һәм элек үз өстенә алган гавами-хокукый йөкләмәләрдән баш тарта ала дигәнне аңлатмый. Киресенчә, аларны саклауга бөтен көчен куеп, ул конституцион әһәмиятле кыйммәтләр, гавами һәм шәхси мәнфәгатьләр балансын табарга, әгәр дә, Россия Федерациясе субъекты бюджеты торышын исәпкә алып, бу объектив мөмкин түгел икән, һәрхәлдә, законнар белән җайга салуга нигезләнеп көткән һәм тиешле социаль ярдәм чараларын алуга исәп тоткан затлар өчен тискәре нәтиҗәләрне мөмкин кадәр йомшартырга тиеш. Башкача булуы социаль дәүләт нигезенә каршы килү генә түгел, Россия Федерациясе Конституциясенең законнарның мәгънәсен, эчтәлеген һәм кулланылышын билгеләүче 2 һәм 18 статьяларыннан килеп чыга торган һәм гавами хакимият органнарына мөрәҗәгать ителгән кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклауны тәэмин итү таләбе белән дә аерылыр иде (2018 елның 27 мартындагы 13-П номерлы Карар).

Шулай итеп, социаль ярдәмнең теге яки бу өстәмә чарасын юкка чыгарып, Татарстан Республикасы закон чыгаручысына алга таба социаль ярдәм чараларын, аерым алганда, торак субсидиясен бирүнең элек билгеләнгән шартларын үзгәрткәндә,

гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын хуплау принцибын сакларга мөмкинлек бирә торган компенсация механизмын күздә тотарга кирәк, ул хокукый җайга салуның нигезле тотрыклылыгын саклауны һәм гамәлдәге нормалар системасына законсыз үзгәрешләр кертүгә юл куелмауны, шулай ук гражданнарга кирәк булган очракта, аерым алганда, вакытлыча җайга салу юлы белән, ниндидер бер нигезле күчеш чоры дәвамында кертелә торган үзгәрешләргә җайлашу өчен мөмкинлек бирүне күздә тота.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» законның, аның башлангыч редакциясендә, 8.2 статьясы гамәлдә булган чорда, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә, шул исәптән аз керемлеләр дип танылган гаиләләргә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, бу хакта әлеге Татарстан Республикасы Законында турыдан-туры күрсәтелүгә карамастан, әлеге социаль ярдәм чарасын бирүне күздә тоткан торак субсидиясен исәпләү тәртибе расланмаган булган. Күрсәтелгән тәртип «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән, ягъни мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган закон үзгәрешләре кертелгәннән соң ук расланган. Шуның нәтиҗәсендә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» (башлангыч редакциясендә) Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булу чорында аның 8.2 статьясы нигезендә торак субсидиясе хокукына ия булган инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр мондый хокуктан, аны гамәлгә ашыру тәртибе булмау сәбәпле, файдалана алмаганнар. Бу закон чыгаручы тарафыннан билгеләнгән хокук асылда иллюзор характерда булган дигәнне аңлата. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының игътибарын шуңа юнәлтергә кирәк дип саный: закон нормасын юридик тәэмин итү механизмы булмау гавами хакимият органнарының ирекле каравына китерергә мөмкин, ә бу хокукый дәүләтнең конституциячел принциплары белән туры килми һәм тиешле хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда киләчәктә һич тә ярамый.

4. Йорт кенәгәсеннән өземтә бирү буенча дәүләт (муниципаль) хезмәте Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан электрон рәвештә беренче чиратта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләре һәм оешмалары һәм муниципаль учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан электрон рәвештә күрсәтелә торган хезмәтләрнең (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 17 декабрендәге 1993-р но-

мерлы күрсәтмәсе белән расланган) һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр реестрына кертелергә тиешле һәм электрон формада күрсәтелә торган, аларда дәүләт йөкләмәсе (заказы) яки муниципаль йөкләмә (заказ) урнаштырылган дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 25 апрелендәге 729-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган) җыелма исемлегенә кертелгән.

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, ведомствоара, шул исәптән электрон, дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында үзара бәйләнешне кертү һәм үстерү зарурлыгыннан чыгып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары һәм муниципаль органнар яки мондый хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы аларга караган оешмалар карамагында булган документларны таләп итәргә хокуклы булмавын күздә тоткан, мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы (7 статьяның 1 өлешендәге 2 пункты). Югарыда күрсәтелгән Федераль законда мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль бирелә торган документлар исемлеген билгеләп, федераль закон чыгаручы Россия Федерациясе субъекты законы яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы норматив хокукый акты яисә муниципаль хокукый акт нигезендә күрсәтелгән исемлектән документлар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып алынырга мөмкинлеген (7 статьяның 6 һәм 6.1 өлешләре) күздә тоткан.

Шул ук вакытта закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле мәгълүматка һәм документларга, һәм, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булганлыктан, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы документларга бүлеп муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган документларның тулы исемлеге муниципаль хезмәт күрсәтү стандартында билгеләнә, ул, үз чиратында, административ регламент структурасына керә («Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 12 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты һәм 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты).

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән расланган (башлангыч редакциясендә) Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.9 пунктындагы өченче абзацы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган белешмә (өземтә) — шәхси торак йортларда яшәүчеләргә бирелә торган гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт кенәгәсеннән өземтә, вафат булучының яшәгән уры-

ныннан вафат булган көненә белешмә, алдагы яшәү урыныннан белешмә.

Административ регламентның шикаять белдерелә торган нигезләмәләре буенча йорт кенәгәсеннән өземтә бирү өчен мөрәҗәгать итүче шул исәптән йорт кенәгәсен дә бирергә тиеш.

- 8 бүлегендәге 2 пункты, аңлылык (С), коммуникацияләр (К) һәм куркынычсызлык (V) коэффициентларына бәйле рәвештә күпфатирлы йортлар өчен Программаны гамәлгә ашыру чиратын билгеләүгә йогынты ясый торган критерийлар эчтәлегенең билгесезлеге өлешендә;

- 9 бүлегендәге 1 пункты, аны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау датасын билгеләми торган һәм күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан гамәлгә ашыруның еллык Планына әлеге йортны кертү өчен Программада катнашу турында мөрәҗәгатьне ел саен җибәрү турындагы таләпне үз эченә алган дәрәҗәдә;

- 9 бүлегендәге 2 пунктның «Г» һәм «Б» пунктчалары, күпфатирлы йортны Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планына кертүгә аның милекчеләренең ачыктан-ачык ризалыгы булып нәрсә саналуы, ул кая һәм нинди формада белдерелергә тиешлеге өлешендә, шулай ук Программада күпфатирлы йорт чиратлылыгының рейтинг күрсәткеченә һәм аны еллык Планга кертү күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга милекчеләрнең ризалыгыннан бәйле булуының билгесезлеге өлешендә.

2. Җирле үзидарә оештыруның гомуми хокукый, оештыру һәм икътисадый принципларын билгели торган «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү максатларында җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү вәкаләтләренә ия дип каралган (17 статьяның 1 өлешендәге 1 пункты). Югарыда аталган Федераль законның 43 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты, 44 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты һәм 3 өлешенең нигезләмәләре буенча муниципаль берәмлек уставы муниципаль хокукый актлар системасына керә, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителә һәм муниципаль хокукый актларның төрләрен, кабул итү (бастырып чыгару), рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибен билгели. Шундый ук нормалар «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның

28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 өлешендәге 6 пунктында һәм 7 статьясындагы 3 өлешендә шулай ук каралган.

Шулай итеп, Уставны кабул итеп һәм әлеге Уставның 81 статьясында муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибен беркетеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы — Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы үзенә федераль һәм республика законнары белән бирелгән вәкаләтләр кысаларында эш иткән.

3. Уставның 81 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль хокукый актлар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә. Китерелгән норматив нигезләмә әлеге статьяның 10 өлеше белән, шулай ук Уставның муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибен регламентлый торган башка нигезләмәләре белән аерылгысыз хокукый бердәмлектә тора, ул кабул ителгән муниципаль хокукый актның алга таба үз көченә керүе өчен төп шарт буларак бастырып чыгару (халыкка җиткерү) датасын күрсәтү кирәклеген күздә тота. Шул ук вакытта Уставның 81 статьясындагы 10 өлешендә турыдан-туры мондый таләп булмау үзеннән-үзе норматив хокукый актны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) датасын күрсәтү мәҗбүри булган һәркем өчен бер булган тәртипне сакламау мөмкинлегенә юл куймый.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 10 өлеше, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәне исәпкә алып, кабул ителгән норматив хокукый актны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырганда аны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) датасын күрсәтүнең мәҗбүрилеге кире кагылмый һәм шуның белән кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең хокукларын юкка чыгармый, киметми һәм башкача бозмый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Уставның 81 статьясындагы 10 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану һәм аның конституциячел-хокукый мәгънәсен ачыклау Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибен хокукый җайга салуны камилләштерүгә комачауламавына игътибар итә. Шуңа бәйле

рәвештә Уставка басма массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга (халыкка җиткерелә) торган муниципаль хокукый актлар мөнәсәбәтендә инде билгеләнгәнгә (Уставның 81 статьясындагы 9 өлешенең икенче абзацы) тиңдәш булган кабул ителгән муниципаль хокукый актны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) аны урнаштырганда бастырып чыгару (халыкка җиткерү) көнен күрсәтү мәҗбүрилеген регламентлаштыра торган нигезләмәләр кертү муниципаль хокукый актларны басма массакүләм мәгълүмат чараларында да, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле рәсми ресурсларда да бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) бертөрле алым кулланылуга ярдәм итәр иде һәм гражданнар тарафыннан аңлауда билгесезлеккә китермәс иде.

4. Татарстан Республикасы Конституциясенең 10, 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләре буенча Татарстан Республикасында җирле үзидарә танылa һәм гарантияләнә, ул үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен тәэмин итә, җирле үзидарә органнары муниципаль милек белән мөстәкыйль идарә итә, җирле бюджетны формалаштыралар, раслыйлар һәм үтиләр. Шундый ук нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 12, 130 (1 өлеш) һәм 132 статьяларында беркетелгән.

Күрсәтелгән хокукый җайга салуга 1985 елның 15 октябрендәге Европа җирле үзидарә хартиясе (Россия Федерациясе өчен 1998 елның 1 сентябрендә үз көченә кергән) нигезләмәсе тәңгәл килә, аның нигезендә җирле үзидарә органнары үзләренең вәкаләтләре өлкәсендәге һәм нинди дә булса башка хакимият органы карамагында булмаган теләсә нинди мәсьәлә буенча үз инициативасын гамәлгә ашыру өчен законда билгеләнгән чикләрдә тулысынча ирекле эш итәләр (4 статьяның 2 пункты).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон эчтәлегеннән күренгәнчә, җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар кабул ителә, алар системасына, шул исәптән, җирле администрациянең һәм башка җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының муниципаль берәмлек уставында каралган хокукый актлары керә (7 һәм 43 статьялар).

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясындагы 1 пункты нигезендә муниципаль программаларны раслау турыдан-туры муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе вәкаләтләренә кертелгән.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары

белән кабул ителгән, Программа кабул ителгән вакытта гамәлдә булган редакциясендә, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Уставта җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр бирелгән Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә башкарма-боеру органы булып Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тора, дип караган иде (42 статьяның 1 пункты) (алга таба шулай ук — Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты).

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәләрнең 9 статьясының 2 пункты һәм 29 статьясындагы 1 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре буенча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты район бюджеты хисабына гамәлгә ашырыла торган муниципаль программаларны раслый һәм аларны гамәлгә ашыру срокларын, муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен билгели.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган Программаны кабул итеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 статьясы (беренче өлеш) нигезләмәләренә таянып, федераль һәм республика законнары нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтләрне дөрес гамәлгә ашырган.

5. Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (өченче өлеш) һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 15 статьясы (3 өлеш) нигезендә, кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый актлар, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмыйлар.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, дәүләт исеменнән норматив хокукый актны гавами хакимиятнең компетентлы органы тарафыннан халыкка җиткерү таләбе хокукый билгеләнешнең гомумтанылган принцибына бәйле, аның нигезендә дәүләтнең һәм шәхеснең мөнәсәбәтләре билгеләнә һәм җәмәгатьчелеккә хәбәр итү әлеге норматив хокукый актның кабул ителүе һәм бәян ителгән тулы текстының гамәлгә кертелергә тиешлеген аңлата. Шул очракта гына аның гамәлдә булуы кагыла торган затларга законны белмәү аны бозган өчен җаваплылыктан азат итми дигән гомумхокукый презумпция кагыла. Норматив хокукый актның гамәлдә булуы яисә булмавына карата билгесезлек аны саклауда, үтәүдә һәм куллануда бертөрлелекне тәэмин итә алмый һәм, димәк, хокук куллану практикасында каршылык китереп чыгара, аны зыянлы максатта һәм башбаштакланып файдалану мөмкинлеген тудыра, конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен киметә, тигезлек һәм хокук өстенлеге принципларын бозуга китерә (2012 елның 27 мартындагы 8-П номерлы Карар).

Татарстан Республикасы Конституция суды бу конститу-

циячел күрсәтмә кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен яклау гарантияләренең берсе булып тора һәм ул императив характерга ия дип шулай ук берничә тапкыр билгеләп үтте (2006 елның 7 мартындагы 19-П номерлы, 2012 елның 21 февралендәге 47-П номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 61-П номерлы һәм 2017 елның 28 апрелендәге 73-П номерлы карарлар).

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы Конституциясенә шул исәптән аларны кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча туры килү-килмәвен билгели.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның үзара бәйләнештәге 47 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләре белән 44 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты эчтәлегеннән аңлашылганча, җирле үзидарә органнарының кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылган һәм федераль закон белән таратылуы чикләнә торган белешмәләре булмаган норматив хокукый актлары тиешле муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнгән тәртиптә тулы тексты белән басылып чыкса гына гомуми танышу өчен рәсми басылып чыккан дип танылырга мөмкин, уставта шул исәптән муниципаль хокукый актларның төрләре, кабул итү (нәшер итү), рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибе билгеләнергә тиеш.

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибе Программа кабул ителгән вакытка Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 5 мартындагы 492 номерлы карары редакциясендә) карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән җайга салынган. Әлеге Уставның 73 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләре нигезендә кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль хокукый актлар аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә, ул түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

— хокукый акт текстын Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары гамәлгә куйган басма массакүләм мәгълүмат чараларында йә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә таратыла торган башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару. Хокукый акт текстын башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарганда әлеге бастырып чыгаруның рәсми булуы хакында тамга булырга тиеш;

— хокукый акт текстын «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы гамәлдә, аның 81 статьясындагы 9 пунктының 4 абзацы нигезендә, муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) чыганаклары исемлегенә, элек гамәлдә булган Уставта беркетелгәннәрдән тыш, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) да керә.

Китерелгән хокукый җайга салу нигезендә «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган карары, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының аңа үзгәрешләр кертелгән барлык башка карарлары кебек үк, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару чыганагы буларак билгеләнгән интернет-ресурсларда аларның текстларын урнаштыру юлы белән рәсми бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) (алга таба — «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтлар).

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 5 мартындагы 492 номерлы карары редакциясендә) карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 73 статьясындагы 4 һәм 9 өлешләре нигезендә, һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары, шул исәптән, исеме, аңа кул кую датасы, теркәү номеры булырга тиеш. Шундый ук нигезләмәләр хәзерге вакытта гамәлдә булган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кабул ителгән 81 статьясындагы 4 пунктында да бар.

«Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда урнаштырылган 218 һәм 895 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының график сурәтләрендә югарыда күрсәтелгән реквизитлар юк, ә нәкъ менә аларга кул кую датасы һәм теркәү номерлары юк.

«2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары Рәсми порталда 03-03-415 номеры белән урнаш-

тырылган иде. Карарның әлеге номеры «“2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында” Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 февралендәге 155 номерлы һәм «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары белән аңа үзгәрешләр керткәндә соңрак яңадан кайтарылган. Ләкин Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгатенә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан дәгъва белдерелә торган карарның 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы теркәү номеры белән рәсми тексты җибәрелде. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының “2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында” 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карарының 1, 2 нче кушымталарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 15 ноябрендәге 2335 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларында шикаять белдерелә торган карарның реквизиты сыйфатында шулай ук 415 номеры күрсәтелгән.

Татарстан Республикасы Конституция суды элегрәк билгеләп үткәнчә, норматив хокукый актларны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибен үтәү — кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау механизмының аерылгысыз элементы, шуңа күрә кабул ителә торган актның тулы һәм төгәл реквизитларын аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле рәсми ресурсларда бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) шул исәптән график сурәтендә күрсәтү андый яклауның нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итә һәм ул мәҗбүри (2017 елның 28 апрелендәге 73-П номерлы карар).

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Суды позициясенә дә тулысынча туры килә, ул үзләренең эчтәлеге һәм (яки) формасы буенча хокукый нормаларның формаль билгеләнеше, төгәллеге, ачыклыгы, бер мәгънәдә булуы һәм гамәлдәге хокукый җайга салу системасында аларның яраклашканлыгы критерийларына җавап бирми торган закон нигезләмәләре аларны төрле мәгънәдә аңлату һәм ирекле куллану мөмкинлеген булдыралар һәм шуның белән гражданнарның конституциячел хокукларын бозуга китерәләр дип берничә тапкыр билгеләп үтте (2012 елның 29 июнендәге 16-П номерлы, 2013 елның 14 маендагы 9-П номерлы карарлар һ.б.).

Югарыда күрсәтелгән хокукый позицияләрне исәпкә алып, дәгъва белдерелә торган муниципаль хокукый актларны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) китерелгән җитешсезлекләр аларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибен бозуны күрсәтә, әмма бу бозулар шикаять белдерелә торган актларның эчтәлеген гражданнар игътибарына җиткермәүне һәм аларның аның белән танышу мөмкинлеге булмавын расламыйлар. Әлеге актларның реквизитлары аларның график сурәтләрендә түгел, ә турыдан-туры «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларында күрсәтелү факты үзеннән-үзе рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе буенча аларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану өчен җитәрлек нигез дип санала алмый, чөнки объектив рәвештә гражданнарга аларның хокукларына, ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылучы карала торган муниципаль хокукый актлар белән танышу мөмкинлеген гамәлгә ашыру өчен каршылыклар тудырмый.

Мондый хәлләрдә Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарын, шулай ук «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын, аларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе буенча, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Конституция суды хокукый нормаларның эчтәлеген бәян иткәндә төгәлсезлектә, тулы булмауда һәм корректлы булмауда чагылган муниципаль хокукый актларның юридик техникасы камил булмау нормалар эшләү сыйфаты түбәнәюгә һәм хокукый җайга салуда тигезлек бозылуга китерүенә игътибар итәргә кирәк дип саный. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына, шул исәптән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына, үзләре кабул итә торган муниципаль норматив хокукый актларга игътибарлырак, төгәлрәк һәм җаваплырак карарга кирәклеген билгеләп үтү мөһим дип саный.

6. Россия Федерациясе Конституция Суды үзенең карарларында берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, җирле үзидарәнең конституциячел билгеләнеше халыкның уртак көнкүреше территориясе буларак муниципаль берәмлек чикләрендә социаль-икътисадый бурычларны чишү белән беррәттән кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен саклау һәм яклау, кешегә лаеклы тормыш һәм иркле үсеш өчен шартлар тудыру бурычларын нәтиҗәле гамәлгә ашыруда чагыла (2011 елның 29 мартындагы 2-П номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге 26-П номерлы һәм 2016 елның 26 апрелендәге 13-П номерлы карарлар).

Мондый алым җирле үзидарә органнарының, шул исәптән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы чикләрендә урнашкан күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен карап тоту һәм ремонтлау тәртибен регламентлаучы норматив хокукый актларның эчтәлеген һәм мәгънәсен алдан билгели.

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 35 пункты нигезләмәләре буенча муниципаль программа муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсешенең бурычлары, башкару сроклары, башкаручылары, ресурслары буенча һәм максатларга иң нәтиҗәле ирешүне һәм бурычларны хәл итүне тәэмин итүче планлаштырылган чаралар комплексын үз эченә алган стратегик планлаштыру документы булып тора. Әлеге Федераль законның 7 статьясындагы 13 пункты нигезендә программалы-максатчан принцип социаль-икътисадый үсешнең өстенлекләрен һәм максатларын билгеләүне, максатлары, гамәлгә ашыру сроклары буенча үзара бәйле муниципаль программалар әзерләүне һәм аларны финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын билгеләүне аңлата.

Дәгъва белдерелә торган Программа нигезләмәләре эчтәлегеннән күренгәнчә, аны кабул итү сыйфатлы ял өчен уңайлы шартлар булдыру, даими яшәү урыны янындагы территорияләрдә халыкның югары көнкүреш культурасын формалаштыру, халыкның ишегалды эчендәге территорияләрен төзекләндерүдә һәм тәртип саклауда катнашуы аша аның актив гражданлык позициясен формалаштыру максатларына бәйле.

Шуңа бәйле рәвештә Программада ишегалды территорияләрен комплекслы төзекләндерү буенча төп бурычлар билгеләнгән, шулай ук аларны тормышка ашыру чаралары һәм механизмы ачыкланган. Программаны тормышка ашыру механизмы элементларының берсе — аны үткәрүнең этаплылыгы, анда аларның ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча эшләр башкару планлаштырылган күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләү кирәклеге дә кертелә.

Федераль дәрәҗәдә дә, республика дәрәҗәсендә дә Программаны гамәлгә ашыру өчен күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләү критерийларына таләпләр билгеләнмәгәнлектән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, үзенә бирелгән дискрецион вәкаләтләр кысала-

рында эш итеп, аларны мөстәкыйль билгеләгән. Шуның белән бергә Программаның эчтәлеге максатларга ирешү нәтиҗәләре һәм анда билгеләнгән конкрет бурычларны хәл итү белән тәңгәл килергә тиеш.

6.1. Программаның мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган 8 бүлегендәге 1 пунктында каралганча, беренче чиратта Программаны гамәлгә ашыру «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы капиталь ремонт ясалган күпфатирлы йортлар өчен каралган; йортларның әлеге төркем эчендәге күпфатирлы йортларның чираты гомуми тәртиптә исәпләнгән сан рейтингы зурлыгы нигезендә формалаштырылган.

Программаның 3 бүлегендә каралганча, Программа башка программалар һәм чаралар белән үзара бәйләнештә гамәлгә ашырыла, алар кысаларында инфраструктура үзгәрешләре тормышка ашырыла. Шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган нигезләмәне күрсәтелгән аспектта Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясы нигезләмәләре, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 8 статьялары белән, шулай ук аларны үстерү өчен кабул ителгән «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән системалы бердәмлектә карарга кирәк. Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының күрсәтелгән карарының V бүлегендәге 1 пунктының 17 пунктчасы нигезендә күпфатирлы йортка комплекслы капиталь ремонт үткәргәндә йорт яны территориясен төзекләндерү (балалар өчен уен мәйданчыклары һәм спорт комплекслары урнаштыру белән) күздә тотыла.

Шулай итеп, йорт яны территорияләрен саклау һәм яңарту өлкәсендә төп юнәлеш — ишегалды территорияләрен комплекслы төзекләндерү икәнен истә тотып, әлеге өстенлекне кертү капиталь ремонт инде үткәрелгән күпфатирлы йортларда финанс кертемнәренең нәтиҗәлелеге һәм төзекләндерү элементларының сакланышы фикерләренә нигезләнгән, чөнки бу очракта гына күпфатирлы йортка капиталь ремонтны, аның йорт яны территориясен төзекләндерүне дә кертеп, тулысынча һәм комплекслы төгәлләү турында сүз барырга мөмкин, бу үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый һәм, димәк, Программаның 8 бүлегендәге 1 пунктының дәгъва белдерелә торган нигезләмәсе мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән аспектта Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми. Мондый алым 1966 елның 16 декабрендәге Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактны гамәлгә ашы-

руны тикшереп торучы Кеше хокуклары буенча комитетның хокук куллану практикасына туры килә, аның нигезендә закон каршында тигез булу хокукы һәм бернинди дискриминациясез законны тигез яклау хокукы мөрәҗәгатьтәге теләсә кайсы аерымлык дискриминацияле дигәнне аңлатмый, шуңа күрә резонлы һәм объектив критерийларга нигезләнгән дифференциация Пактның 26 статьясы мәгънәсе буенча тыелган дискриминация белән бер үк түгел (Комитетның 1987 елның 9 апрелендәге 182/1984 номерлы карарының 13 пункты).

6.2. Аңлылык (С), коммуникацияләр (К) һәм куркынычсызлык (V) коэффициентларына (8 бүлекнең 2 пункты) бәйле рәвештә эшләр башкару өчен күпфатирлы йортлар өчен Программаны гамәлгә ашыру чиратын билгеләү критерийларының билгесезлеге турындагы мәсьәләне карап, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

6.2.1. Дәгъва белдерелә торган нормада аңлылык (С) коэффициенты күпфатирлы йортта күпфатирлы йорт Советының булуына бәйле рәвештә куелган: әгәр күпфатирлы йорт Советы сайланган булса, аңлылык (С) коэффициенты 0,5 кә тигез, әгәр ул сайланмаган булса, аңлылык (С) коэффициенты 1 гә тигез.

Россия Федерациясе Торак кодексының 161.1 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, әгәр әлеге йортта дүрттән артык фатир булса һәм шул ук вакытта анда торак милекчеләре ширкәте оештырылмаса яисә әлеге йорт торак кооперативы яисә башка төрле кулланучылар кооперативы тарафыннан идарә ителмәсә, күпфатирлы йортта урыннарның милекчеләре күпфатирлы йортның советын сайларга бурычлы.

Дәгъва белдерелә торган норманың 2 пункты нигезләмәләре күпфатирлы йортларның чиратлылыгы рейтингның минималь күрсәткечләреннән максималь күрсәткечләргә нисбәте буенча (ягъни сан күрсәткече азрак булган саен, Программа нигезендә эшләр шулкадәр алданрак башкарыла) аралау юлы белән билгеләнә. Шикаять белдерелә торган норманың сүзгә-сүз аңлатмасыннан күренгәнчә, күпфатирлы йорт Советы сайланган йортлар түбән санлы рейтинг җыялар, ә, мәсәлән, йорт белән идарә итү ысулы буларак торак милекчеләре ширкәте сайланган йортлар белән чагыштырганда да, димәк, Программага алданрак эләгәләр. Татарстан Республикасы Конституция суды мондый алым нигезле дип танылa алмый дип саный, чөнки әлеге Кодексның башка нормалары белән үзара бәйләнештә Россия Федерациясе Торак кодексының 161.1 статьясы эчтәлегеннән аңлашылганча, күпфатирлы йорт Советы күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең үз-үзләрен оештыру төрләреннән берсе генә булып тора. Шуңа бәйле рәвештә карала торган хокукый җайга салу, асылда, йорт белән идарә итү ысулы буларак идарәче компанияне сайлаган күпфатирлы йортларга өстенлек бирүгә юнәлдерелгән, бу исә акылга ярашлылык һәм гаделлек, юридик тигезлек принципларына җавап бирми, һәм бу, Программада куелганга караганда, турыдан-туры каршылыклы максатларга китерергә мөмкин, чөнки үз эчтәлегеннән чыгып, күпфатирлы

йорт белән идарә итү ысулы буларак торак милекчеләре ширкәтен яисә торак кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы белән идарә итүне сайлаган күпфатирлы йортларда урыннарның милекчеләре өчен хокукый хәлдә нигезсез дифференциация тудыра.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Торак кодексының 161.1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, әгәр календарь елы дәвамында анда урыннарның милекчеләре тарафыннан күпфатирлы йорт советын сайлау турында карар кабул ителмәсә яки тиешле карар гамәлгә ашырылмаган булса, җирле үзидарә органы өч айлык срокта күпфатирлы йортта урыннарның милекчеләренең гомуми җыелышын чакырта, аның көн тәртибенә бу йортта күпфатирлы йорт советын, шул исәптән бу йорт советының рәисен сайлау турында яки бу йортта торак милекчеләре ширкәтен оештыру турында мәсьәләләр кертелә. Димәк, үзенең сүзгә-сүз атамасына — «аңлылык коэффициенты», шулай ук Программада каралган бурычларның берсенә, ә атап әйткәндә — халыкны үзләренең күпфатирлы йортлары белән идарә итүгә тартуга карамастан, күрсәтелгән коэффициент, киресенчә, урыннарның милекчеләре үзләре яши торган күпфатирлы йорт белән идарә итү эшләрендә активлык һәм аңлылык күрсәтмәгән күпфатирлы йортларда милекчеләре күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау буенча мөстәкыйль инициатива күрсәткән йортлардагыга караганда элегрәк Программа буенча эшләр башкару өчен мөмкинлек тудыра.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды шикаять белдерелә торган хокукый җайга салу күпфатирлы йорт Советы сайланган күпфатирлы йорт милекчеләрен Программага кертелгән күпфатирлы йортларның башка милекчеләренә карата күрә торып тигезсез хәлгә куя дигән нәтиҗәгә килә.

Шулай итеп, күпфатирлы йортлар өчен Программаны гамәлгә ашыру чиратын билгеләү критерийларының билгесезлеге өлешендә Программаның дәгъва белдерелә торган 8 бүлегендәге 2 пункты, күпфатирлы йорт Советын сайлауга бәйле рәвештә (аңлылык (С) коэффициенты) гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә.

6.2.2. Шикаять белдерелә торган нормада коммуникацияләр (К) коэффициенты хисаплар бирү буенча (ягу сезонына, запросларга, мәгълүматны ачарга һ.б. әзерләнгәндә) җирле үзидарә органнарының күпфатирлы йорт адресына карата кисәтүләре булуга, шулай ук күпфатирлы йорт вәкилләренең җирле үзидарә органнары үткәрә торган чараларда (киңәшмәләрдә, семинарларда, очрашуларда һ.б.) даими катнашучылар булу-булмавына бәйле рәвештә куелган. Кисәтүләр булса, шулай ук әлеге чараларда катнашмаган очракта, коммуникацияләр (К) коэффициенты 1 гә тигез, кисәтүләр булмаган очракта коммуникацияләр (К) коэффициенты 0,5 кә тигез.

Дәгъва белдерелә торган норманы анализлау әлеге коэффи-

циентны билгеләү хокукый нигезгә ия түгел дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә, чөнки күпфатирлы йортка карата җирле үзидарә органының кисәтүләрен алырга мөмкин булган хисапларны тапшырганда күпфатирлы йортның бозулары дәрәҗәсен дөрес бәяләргә мөмкинлек бирми, җирле үзидарә органнары үткәрә торган чараларда катнашу даимилеге төшенчәләрен ачмый, шулай ук аларда катнашуны раслау формасын билгеләми.

Шуңа бәйле рәвештә шикаять белдерелә торган норма, аның сүзгә-сүз аңлатмасыннан чыгып, хокук куллану органына әлеге коэффициентның эчтәлеген һәм күрсәткечләрен үзенчә исәпкә алырга һәм бәяләргә мөмкинлек бирә торган вариатив характерга ия, бу җирле үзидарә органының конкрет күпфатирлы йортларда яшәүчеләргә мөнәсәбәте кебек субъектив фактор булуын, димәк, Программаны гамәлгә ашырганда мондый күпфатирлы йортның чиратлылыгын билгеләү булуын да күрсәтә.

Татарстан Республикасы Конституция суды, мондый алымны нигезле дип танырга ярамый, чөнки дәгъва белдерелә торган норма эчтәлегенең билгесезлеге хокук куллану процессында чикләнмәгән каралуга юл куя һәм законсызлыкка, димәк, тигезлек һәм закон өстенлеге принципларының бозылуына китерә дип саный.

Алай гына да түгел, мондый алым норматив нигезләмәләргә карата куела торган ачыклык һәм каршылыксызлык таләпләре белән туры килми, аларда законның гамәлдә булу механизмы тиешле хокук мөнәсәбәтләре субъектларына конкрет норматив нигезләмәләр эчтәлегеннән яисә норматив нигезләмәләрнең күзгә күренеп торган үзара бәйләнешендә булган системадан чыгып аңлаешлы булырга тиешлеге, чөнки конституциячел тигез хокуклылык хокукый норманы барлык хокук кулланучылар тарафыннан бертөрле аңлау һәм аңлату шарты белән генә тәэмин ителергә мөмкин булуы күздә тотыла (Россия Федерациясе Конституция Судының 2013 елның 27 июнендәге 15-П номерлы, 2013 елның 23 декабрендәге 29-П номерлы, 2014 елның 22 апрелендәге 12-П номерлы һ.б. карарлар).

Шулай итеп, Программаның мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган 8 бүлегендәге 2 пункты, Программаны гамәлгә ашырганда, әлеге мәсьәләне хәл итүне хокук кулланучы каравына калдырып, күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләү өчен коммуникацияләр (К) коэффициентының билгесезлеге өлешендә, гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә, аның 2, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 32 һәм 55 статьяларына туры килми.

6.2.3. Дәгъва белдерелә торган нормада куркынычсызлык (V) коэффициенты милекчеләрнең күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга ризалыгына бәйле итеп куелган — әгәр күпфатирлы йортта видеокүзәтү урнаштыру өчен кворум җыелса, куркынычсызлык (V) коэффициенты 0.5 кә тигез, әгәр

кворум җыелмаган булса, куркынычсызлык (V) коэффициенты 1 гә тигез.

Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясындагы 1.1 өлеше нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләренең гомуми милкен тиешле тәртиптә тоту Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә башкарылырга тиеш һәм күпфатирлы йортның ышанычлылыгына һәм иминлегенә, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең иминлегенә һәм башкаларга карата таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тиеш. Уртак милекне карап тотуның хокукый шартлары Россия Федерациясе Торак кодексының 39 статьясындагы өченче өлеше буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта уртак милекне карап тоту кагыйдәләре белән билгеләнгән, алар нигезендә урыннар милекчеләре уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча гамәлләрне мөстәкыйль башкарырга яки күпфатирлы йорт белән идарә итүнең сайланган ысулын исәпкә алып, уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару өчен башка затларны җәлеп итәргә хокуклы (12 пункт), шулай ук гомуми җыелышта хезмәтләр һәм эшләр исемлеген, аларны күрсәтү һәм башкару шартларын, аларны финанслау күләмен расларга тиешләр (17 пункт).

Татарстан Республикасы Конституция суды күрсәткәнчә, күпфатирлы йортны видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү мондый йорттагы урын милекчеләренең бары тик аерым хокукы гына булып тора. Шул ук вакытта видеокүзәтү системасын кертү турындагы карар, видеокүзәтү хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм аның өчен түләү күләме кебек үк, әлеге милекчеләрнең гомуми җыелышында билгеләнгән тәртиптә кабул ителергә һәм тиешле беркетмә белән рәсмиләштерелергә тиеш (2019 елның 25 ноябрендәге 86-П номерлы карар).

Дәгъва белдерелә торган Программа, аны гамәлгә ашырганда, күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләгәндә бу хәлне исәпкә алса да, күпфатирлы йортларның милекчеләренә үзләренең күпфатирлы йортларын видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү бурычын йөкләми.

Шуның белән бергә, шикаять белдерелә торган хокукый нигезләмә Программаның хокукый статусыннан һәм аның эчтәлегеннән килеп чыга, аның нигезендә Программаның нәтиҗәлелеге шул исәптән гражданнар милкенең һәм гомуми йорт милкенең куркынычсызлыгын һәм сакланышын арттыру хисабына, шулай ук аларга контрольне көчәйтү, төзекләндерү объектлары өчен халыкның җаваплылыгын арттыру хисабына да ирешелә. Моннан тыш, Программаны финанслау, шул исәптән, җирле бюджет акчалары хисабына да гамәлгә ашырыла. Мондый шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды, Программаны гамәлгә ашырганда күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләү өчен Программаның 8 бүлегендәге 2 пунктында куркынычсызлык (V) коэффициенты булу, шулай ук

Программаның 9 бүлегендәге 2 пунктының «Б» пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга милекчеләрнең ризалыгына карап, күпфатирлы йортны еллык Планга кертү турындагы таләпнең булуы Программа кысаларында башкарылган йорт яны территорияләрен төзекләндерү эшләренең үзенчәлекле сакланыш гарантиясе булып тора дип саный, бу гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды шуңа игътибар итә: дәгъва белдерелә торган Программаның хокукый эчтәлеге күпфатирлы йорт ишегалдында видеокүзәтү системасы инде урнаштырылган очракларда куркынычсызлык (V) коэффициентын исәпләргә мөмкинлек бирми, бу исә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан аңа тиешле төзәтмәләр кертүен таләп итә.

7. Программаның 9 бүлегендәге 1 пункты нигезләмәләрен, аны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау датасын билгеләми торган һәм күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан аны гамәлгә ашыру еллык Планына әлеге йортны кертү өчен Программада катнашу турында Мөрәҗәгатьне ел саен җибәрү турындагы таләпне үз эченә алган дәрәҗәдә бәяләп, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләргә игътибар итәргә кирәк дип саный.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 статьясындагы 1 өлешенең өченче абзацындагы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре буенча муниципаль берәмлекләрнең бюджет вәкаләтләренә, аерым алганда, җирле бюджет проектын төзү һәм карау, аны раслау, үтәү, тикшереп тору, шулай ук аның үтәлеше турындагы хисапны төзү һәм раслау керә. Шундый ук нигезләмәләр «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законында да бар (7 статьяның 1 өлешендәге 9 пункты, 16 статьяның 1 өлешендәге 1 пункты, 22 статьяның 8 өлешендәге 2 пункты һәм 33 статьяның 4 өлеше).

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәнең 25 статьясындагы 2 пункты һәм 34 статьясындагы 1 пункты нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (район Башкарма комитеты җитәкчесе аша) агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча район Советы каравына чираттагы финанс елына һәм план чорына, шул исәптән муниципаль программаларга нигезләнгән район бюджеты турындагы карар проектын кертә.

Шикаять белдерелә торган норманы югарыда күрсәтелгән Нигезләмә нормалары белән, шулай ук Программаның үзенең, аны финанслау шул исәптән җирле бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла, финанслау күләме ел саен билгеләнә, Програм-

маны гамәлгә ашыруга сарыф ителә торган акчалар бюджет финанславы мөмкинлекләреннән чыгып ачыклана (4 бүлек) дигән башка нигезләмәләре белән системалы бәйләнештә карап, Татарстан Республикасы Конституция суды, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Программаны гамәлгә ашыруның чираттагы елына финанслау лимиты кысаларында күпфатирлы йортлар кертелә торган Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау срокларын билгеләү мәсьәләсендә чикләнмәгән ихтыяр иреккә ия түгел, чөнки аны раслау чираттагы финанс елына Зеленодольск муниципаль районы бюджетын әзерләү һәм раслау срокларына бәйле дип билгеләп үтә.

Югарыда күрсәтелгән бюджетны планлаштыруга кагылышлы нигезләмәләр Программаның дәгъва белдерелә торган 9 бүлегендәге 1 пунктында булган күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан әлеге йортны Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планына кертү өчен анда катнашу турында ел саен Мөрәҗәгать җибәрү турындагы таләпне дә билгели. Моннан тыш, Программаның 9 бүлегендәге 3 пункты нигезендә, еллык Планны финанслау лимитлары Мөрәҗәгатьләр булган барлык күпфатирлы йортларга карата Программаны гамәлгә ашыру эшләрен башкарырга мөмкинлек бирмәгән очракта, Планга Мөрәҗәгатьләр булган йортлар саныннан рейтингның иң зур күрсәткече булган күпфатирлы йортлар кертелми. Бу очракта мондый йортны киләсе еллык Планга кертү мөмкинлеге, гомуми тәртиптә санлы рейтинг күләменнән чыгып, яңа формалаштырыла торган чират белән билгеләнә. Шул ук вакытта, Программаның 7 бүлеге нигезендә аңа Зеленодольск шәһәре территориясендә урнашкан, йорт яны территорияләре норматив хокукый актлар таләпләренә туры китереп, асфальт катламын торгызу (ремонтлау, урнаштыру) буенча эшләргә мохтаҗ булган барлык күпфатирлы йортлар да кертелүен, ә еллык Планга милекчеләре тиешле Мөрәҗәгатьләр биргән күпфатирлы йортлар кертелүен исәпкә алырга кирәк.

Шулай итеп, Программаның 9 бүлегендәге 1 пунктының карала торган нигезләмәсе, ул аны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау датасын билгеләми торган дәрәҗәдә, шулай ук әлеге карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планына әлеге йортны кертү өчен анда катнашу турында Мөрәҗәгатьне ел саен җибәрү таләбе булган дәрәҗәдә үзеннән-үзе кеше һәм гражданның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең ул күрсәткән аспектта конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый. Моның белән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау срокларын төгәлләштерү өлешендә, шикаять белдерелә торган нигезләмәгә тиешле төгәллек кертү юлы белән, әлеге хокукый җайга салуны камилләштерү мөмкинлеге юкка чыгарылмый.

8. Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләренең гомуми җыелышы күпфатирлы йорт белән идарә итү органы булып тора, ул күпфатирлы йорт белән идарә итү максатларында көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм тавышка куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү юлы белән үткәрелә (44 статьяның 1 өлеше). Әлеге статьяның 2 өлешендәге 2.1 пункты нигезендә күпфатирлы йорттагы урын милекчеләренең гомуми җыелышы вәкаләтләренә күпфатирлы йорт урнашкан һәм күпфатирлы йорттагы урын милекчеләренең гомуми милкенә караган җир кишәрлеген төзекләндерү, шул исәптән күрсәтелгән җир кишәрлегендә яшелләндерү һәм төзекләндерү элементларын урнаштыру, аларга хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү турында карарлар кабул итү керә. Гомуми җыелыш үткәрүне оештыру (45 статьяның 2, 4 һәм 5 өлешләре) һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен беркетмә белән рәсмиләштерү (46 статья) бурычы йөкләнгән күпфатирлы йортның урын милекчеләре генә мондый җыелышның инициаторы булып тора ала.

Торак законнарының китерелгән нигезләмәләрен исәпкә алып, дәгъва белдерелә торган Программаның 9 бүлегендәге 2 пункты, асылда, аны еллык Планга кертү турында карар кабул итү өчен күпфатирлы йорттагы урын милекчеләренең гомуми җыелышына тикшерүгә чыгарылырга тиешле мәсьәләләр даирәсен билгели. Шул ук вакытта куелган мәсьәләләр буенча тавыш бирүнең гомуми җыелыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә торган нәтиҗәләре, шикаять белдерелә торган нигезләмәдән чыгып, күпфатирлы йортны еллык Планга кертү өчен ачыктан-ачык белдерелгән ризалык дип санала ала, бу үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга:

— Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 10 өлешен, чөнки ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, әлеге норма норматив хокукый актны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) датасын күрсәтү мәҗбүри булган һәркем өчен бер булган тәртипне сакламау мөмкинлегенә юл куймый;

— «2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы, «2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары, аларны рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча;

— Программаның 8 бүлегендәге 1 пункты, аның нигезендә, беренче чиратта, аны гамәлгә ашыру комплекслы капиталь ремонт ясалган күпфатирлы йортлар өчен каралган;

— Программаның 8 бүлегендәге 2 пункты, күпфатирлы йортта видеокүзәтү системаларын урнаштыруга кворум җыелуга бәйле рәвештә, Программа буенча күпфатирлы йортның чиратлылыгын билгеләгәндә, санлы рейтинг күләменә йогынты ясый торган куркынычсызлык (V) коэффициентын билгеләү өлешендә;

— Программаның 9 бүлегендәге 2 пунктының «Б» пунктчасы, ул күпфатирлы йортны, күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга милекчеләрнең ризалыгыннан чыгып, еллык Планга кертү турындагы таләпне үз эченә ала;

— Программаның 9 бүлегендәге 1 пункты, ул аны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау датасын билгеләми торган дәрәҗәдә, шулай ук күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан гамәлгә ашыруның еллык Планына әлеге йортны кертү өчен Программада катнашу турында Мөрәҗәгатьне ел саен җибәрү турындагы таләпне үз эченә алган дәрәҗәдә;

— Программаның 9 бүлегендәге 2 пункты, аның нигезендә мөрәҗәгатьтә күпфатирлы йортны еллык Планга кертүгә ачыктан-ачык белдерелгән ризалык булырга тиеш.

2. Программаның 8 бүлегендәге 2 пунктын, анда билгеләнгән аңлылык (С) һәм коммуникацияләр (К) коэффициентларына бәйле рәвештә, күпфатирлы йортлар өчен Программаны гамәлгә ашыру чиратлылыгын билгеләү критерийларының билгесезлеге өлешендә, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге Карарда бәян ителгән шул таләпләргә нигезләнгән хокукый позицияләрен исәпкә алып — Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлдә булган хокукый җайга салуга әлеге Карардан килеп чыга торган кирәкле үзгәрешләрне кертергә.

4. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан

1.2. Татарстан Республикасы Конституция судының 2020 елның 21 гыйнварындагы 2-О номерлы билгеләмәсе белән гражданин Р.Р. Измайловның шикаяте түбәндәгеләрнең конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга алынган иде: «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 5 пунктының, 8 пунктындагы икенче абзацының; Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы кара-

ры белән расланган Казан шәһәрендә торак урыннарга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пунктының, Законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлегенең алтынчы, җиденче һәм сигезенче абзацларының (әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта), шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 14 октябрендәге 9010 нчы номерлы карары белән расланган Гражданнарга социаль наем шартнамәсе нигезендә муниципаль милектәге торак урынны бирү турында Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый актын әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пунктының һәм Гариза бирүчегә һәм аның гаилә әгъзаларына социаль наем шартнамәсе нигезендә торак урын бирү турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар исемлегенең алтынчы, җиденче һәм сигезенче абзацларының (әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта).

Эшне суд утырышында карый башлаганда мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган административ регламентларга үзгәрешләр кертелгән. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 декабрендәге 4641 номерлы карары белән Торак урыннарга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләренә үзгәрешләр кертелгән, алар нигезендә Административ регламентка 1 нче кушымта яңа редакциядә бәян ителгән. Аларның эчтәлегеннән күренгәнчә, элек Административ регламентка 1 нче кушымтаның сигезенче абзацында булган торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документлар (ордер, шартнамә, торак урынын бирү турында карар һәм башка документлар) бирү бурычына кагылышлы мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган нигезләмә төшереп калдырылган. Әмма мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхси финанс счетын бирү бурычына кагылышлы нигезләмә әлеге Административ регламентка 3 нче кушымтаның I өлешендәге 9 пунктында асылда сакланып калган һәм чагылыш тапкан. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 14 октябрендәге 9010 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 декабрендәге 4652 номерлы карары белән Хокукый акт әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына шулай ук үзгәрешләр кертелгән, аларның эчтәлегеннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхси финанс счетын бирү бурычына кагылышлы нигезләмә фактта әлеге Административ регламентка 3 нче кушымтаның I өлешендәге 9 пунктында сакланган һәм чагылыш тапкан.

Эшне тыңлауга билгеләгәннән соң кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, гражданин Р.Р. Измайлов шикаять буенча төгәлләштерүләр җибәрде, алар нигезендә түбәндәгеләрне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тануны сорый:

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пункты, шулай ук Муниципаль хезмәт, шулай ук хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлегенең (әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта) I өлешенең 8 һәм 9 пунктлары;

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 14 октябрендәге 9010 нчы номерлы карары белән расланган Гражданнарга социаль наем шартнамәсе нигезендә муниципаль милектәге торак урынны бирү турында Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый актын әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пункты, шулай ук Муниципаль хезмәт, шулай ук хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлегенең (әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта) I өлешенең 8 һәм 9 пунктлары.

1.3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында билгеләнгәнчә, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса һәм закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса, Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була.

Әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция суды утырышы барышында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 14 октябрендәге 9010 нчы номерлы карары белән расланган Гражданнарга социаль наем шартнамәсе нигезендә муниципаль милектәге торак урынны бирү турында Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый актын әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының хокукый нигезләмәләре һәм әлеге Административ регламентка кушымталар гражданин Р.Р. Измайловка карата кулланылган булуы яисә кулланылырга мөмкин булуы расланмады.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татар-

стан Республикасы Законының 63 статьясы нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, утырыш барышында мөрәҗәгатьне карауга алудан баш тартуга нигезләр ачыкланса, утырыш барышында мөрәҗәгатьне карауга алудан баш тартуга нигезләр, шуларның берсе — аның мөмкин булу критерийларына туры килмәве ачыкланган очракларда, эш алып баруны туктата.

Димәк, әлеге эш буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 14 октябрендәге 9010 нчы номерлы карары белән расланган Гражданнарга социаль наем шартнамәсе нигезендә муниципаль милектәге торак урынны бирү турында Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый актын әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пунктының һәм әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның алтынчы, җиденче һәм сигезенче абзацларының (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 26 декабрендәге 4652 номерлы карары кабул ителгәнчегә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) конституциячеллеген тикшерү өлешендә эш карау туктатылырга тиеш, чөнки мөрәҗәгать итүченең бу өлештә мөрәҗәгате мөмкин түгел. Моннан күренгәнчә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 14 октябрендәге 9010 нчы номерлы карары белән расланган Гражданнарга социаль наем шартнамәсе нигезендә муниципаль милектәге торак урынны бирү турында Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый актын әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пунктының, Муниципаль хезмәт, шулай ук хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлегенең (әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта) I өлешенең 8 һәм 9 пунктларының конституциячеллеген тикшерү турында аның төгәлләштерелгән таләпләре шулай ук Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан әлеге эштә каралырга тиеш түгеллеге килеп чыга.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, конституциячеллеге дәгъваланучы акт юкка чыгарылган булса яисә эшне карый башлаганчы йә аны карау чорында үз көчен югалткан булса, Татарстан Республикасы Конституция суды башлаган эш туктатылырга мөмкин, моңа бу актның гамәлдә булуы аркасында гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылган очраклар керми. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган шикаять белдерелә торган Административ регламентка кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, шулай ук мөрәҗәгать итүченең шикаятькә төгәлләштерү керткәндә үз таләпләренең бер өлешеннән баш тартуын игътибарга алып, әлеге Административ

регламентның 2.5 пункты нигезләмәләренең, аңа 1 нче кушымтасындагы сигезенче абзацы белән аның үзара бәйләнешендә (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 26 декабрендәге 4641 номерлы карары кабул ителгәнче гамәлдә булган редакциясендә) конституциячеллеген тикшерү өлешендә бу эшне карау туктатылырга тиеш.

Шул ук вакытта, калган өлешендә кертелгән үзгәрешләр, асылда, дәгъва белдерелә торган хокукый җайга салуга кагылмаганнар һәм аның торакка конституциячел хокукын бозуның хокукый нигезе булып торалар, дип уйлаган гражданин Р.Р. Измайлов позициясен исәпкә алып, Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының карала торган нормаларына үзгәрешләр кертү шикаять белдерелә торган нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерүгә комачаулык итә алмый дип саный.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача аңлатып яки хокук куллану гамәлиятендәге мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар:

— «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләре, хокук куллану практикасында аңа бирелә торган мәгънә буенча, шәхси финанс счетын гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлегенә керткән дәрәҗәдә;

— Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 5 пункты, 8 пунктындагы икенче абзацы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан субсидия алучы гражданнарны субсидияләр бүлеп бирелгән гражданнар исемлегенә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кертү шартларын, федераль бюджеттан бүлеп бирелә

торган субвенцияләр исәбеннән торак шартларын яхшырту хокукын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларында алар тарафыннан раслау кирәклеген билгеләп, мондый раслау тәртибен күздә тотмаган, һәм, аларга хокук куллану практикасында бирелә торган мәгънәсе буенча, гражданнарның шәхси финанс счетын тапшырмаган очракта, аларның торак шартларын яхшыртуга хокукын расланмаган дип танырга мөмкинлек биргән дәрәҗәдә;

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пункты нигезләмәләре, аларның Муниципаль хезмәт, шулай ук хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлегенең (әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта) I өлешенең 8 һәм 9 пунктлары белән үзара бәйләнешендә, алар тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле вәкаләтле органнарга аңа яшәү урыны буенча үзе белән бергә теркәлгән барлык гражданнар турында адресы, гражданнарның теркәлү датасы, документны бирү көне күрсәтелгән мәгълүматларны үзенә туплаган документ һәм торак бинаның гомуми һәм торак мәйданын, бирү датасын күрсәтеп, шәхси финанс счеты тапшыру бурычын йөкләгән дәрәҗәдә.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләре социаль яклау һәм торак законнары өлкәләренә кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, икенче һәм бишенче өлешләр).

Россия Федерациясе Торак кодексында, торак турындагы законнар Россия Федерациясе субъектларының кабул ителгән законнарыннан һәм башка норматив хокукый актларыннан тора; Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары әлеге Кодекс, шушы Кодекс нигезендә кабул ителгән башка федераль законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә торак

мөнәсәбәтләрен җайга сала торган нормалар булган законнар һәм башка норматив хокукый актлар кабул итә алалар (5 статьяның 2 һәм 6 өлешләре); торак биналарга мохтаҗ булган гражданнарның җирле үзидарә органында исәбен алып бару тәртибе тиешле Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә (52 статьяның 7 өлеше).

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләрне һәм Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләрне Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә закон чыгарып җайга салу Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына керә (75 статья, 2 пункт).

Шулай итеп, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законында җирле үзидарә органы тарафыннан гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу тәртибен кертеп һәм гражданнарны мондый исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлеген билгеләп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының социаль яклау һәм торак законнары өлкәсендә Россия Федерациясе Конституциясендә билгеләнгән эшләр бүлешүдән чыгып эш иткән һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтен дөрес гамәлгә ашырган.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нормалары шулай ук социаль яклау һәм торак законнары өлкәсенә кагыла.

«Ветераннар турында» Федераль закон нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм 2005 елның 1 гыйнварына кадәр исәпкә баскан сугыш хәрәкәтләре ветераннарын торак белән тәэмин итү вәкаләтләре Россия Федерациясе тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган. Социаль ярдәмнең күрсәтелгән чарасын бирү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга акча федераль бюджетта субвенцияләр рәвешендә карала, ә аны бирү рәвеше Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актлары белән билгеләнә (23.2 статьяның 1, 2 һәм 6 өлешләре).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, аерым алганда социаль тәэминат өлкәсендә, бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый

актларының үтәлешен тәэмин итә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә үтәү мәҗбүри булган карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.

Димәк, Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль законнар нигезендә карый торган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган.

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне норматив хокукый җайга салу әлеге Федераль закон, башка федераль законнар белән, алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләнгән.

Күрсәтелгән Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлеше һәм 13 статьясындагы 15 өлеше белән үзара бәйләнештә 6 статьясы нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар аларны административ регламентлар нигезендә күрсәтергә тиеш; муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе җирле администрация тарафыннан билгеләнә.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенең 1.8 пункты нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә административ регламентлар билгеләнгән тәртиптә Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый акты белән расланалар.

Шулай итеп, Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслап, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзенә федераль законнар нигезендә бирелгән, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтләрне дөрес гамәлгә ашырган.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә. Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы (2 статья); һәркемгә, шул исәптән авырган һәм гарипләнгән очракта социаль тәэминат гарантияләнә

(54 статья, 1 өлеш); һәркем торакка хокуклы; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья, 1 һәм 2 өлешләр).

Россия Федерациясе Торак кодексының 2 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә гражданнарның торакка хокукын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итәләр, шул исәптән: бюджет акчаларын һәм законда тыелмаган башка акча чыганакларын гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен, шул исәптән торак биналар сатып алу яисә төзү өчен билгеләнгән тәртиптә субсидияләр бирү юлы белән файдаланалар (2 пункт).

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча үз вәкаләтләре чикләрендә карарлар кабул итеп, шактый дискрециягә ия, әмма ул тигезлек, гаделлек һәм ярашканлык конституциячел принциплары белән, хокукый җайга салуның билгелелек таләпләре белән, шул исәптән ул тудыра торган хокукый нәтиҗәләрдә дә чикләнгән.

3.1. 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең шикаять белдерелә торган хокукый нигезләмәләрендә гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлеге билгеләнгән. Күрсәтелгән нормалар мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана, чөнки хокук куллану практикасында аларга бирелә торган мәгънә буенча, шәхси финанс счетын гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлегенә кертәләр, шуның белән аның конституциячел хокукларын бозалар.

Россия Федерациясе Конституция Суды үзенең карарларында берничә тапкыр күрсәткәнчә, торакка хокукны гамәлгә ашыру торак законнары актларында беркетелгән аерым таләпләргә бәйле булырга мөмкин (2002 елның 9 апрелендәге 123-О номерлы, 2004 елның 4 мартындагы 80-О номерлы, 2010 елның 15 июлендәге 955-О-О номерлы, 2010 елның 25 ноябрендәге 1543-О-О номерлы һ.б. билгеләмәләр).

Россия Федерациясе Торак кодексының 52 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, граждан тарафыннан, исәпкә алу турында гариза белән бергә, исәпкә алуны гамәлгә ашыручы орган тарафыннан ведомствоара мөрәҗәгатьләр буенча алына торган документлардан тыш, аның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә тору хокукын раслаучы документлар тапшыру кирәклеге шундый таләпләрнең берсе булып тора. Гражданнарны торак исәбенә куюның законлы булуын документаль раслауны күздә тоткан мондый таләп үзеннән-үзе, Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, гражданнарның нинди дә булса конституциячел хокукларын бозмый (2015 елның 16 июлендәге 1697-О номерлы билгеләмә).

Россия Федерациясе Торак кодексының күрсәтелгән нигезләмәсеннән күренгәнчә, гражданнарны торак шартларын яхшыр-

туга мохтаҗлар исәбенә алу өчен кирәкле документларның бер өлеше гражданнар тарафыннан турыдан-туры бирелә, ә бер өлеше торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алучы органнар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә ведомствоара мөрәҗәгатьләр юлы белән соратып алына.

Мондый хокукый җайга салу шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон нигезләмәләре белән дә бәйле, ул ведомствоара, шул исәптән электрон, дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында үзара бәйләнешне кертү һәм үстерү кирәклегеннән чыгып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарның мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, башка дәүләт һәм муниципаль органнар яки мондый хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы аларга караган оешмалар карамагында булган документларны таләп итәргә хокуклы булмавын күздә тоткан; мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы (7 статьяның 1 өлешендәге 2 пункты). Тиешле органнар һәм оешмалар карамагында булган документларны гражданнардан таләп итүне тыеп, федераль закон чыгаручы шул ук вакытта югарыда күрсәтелгән Федераль законда мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль бирелә торган документлар исемлеген беркеткән һәм шул ук вакытта Россия Федерациясе субъекты законы яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы норматив хокукый акты яисә муниципаль хокукый акт нигезендә күрсәтелгән исемлектән документлар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып алынырга мөмкинлеген күздә тоткан (7 статьяның 6 һәм 6.1 өлешләре).

Гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алу өчен кирәкле документларга карата шуны билгеләп үтәргә кирәк, мондый документлар исемлеге федераль закон чыгаручы тарафыннан билгеләнмәгән.

Шуңа бәйле рәвештә, республика закон чыгаручысы, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарга карата Россия Федерациясе Торак кодексында һәм торак законнарының башка норматив хокукый актларында каралган таләпләрдән чыгып, мондый гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алу өчен кирәкле документлар исемлеген беркеткән, шул ук вакытта гражданнарның үз инициативалары буенча нинди документлар тапшырылырга мөмкин булуын, ә тапшырылмаган очракта закон нигезендә күрсәтелгән документлар алар карамагында булган дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан вәкаләтле орган тарафыннан соратып алынуын күздә тоткан.

31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең «д», «е» һәм «ж» пунктлары нигезендә, әлеге статьяның 4.1 өлеше белән үзара бәйләнешендә, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алу өчен кирәкле до-

кументлар арасыннан гражданнар тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырыла торган документларга түбәндәгеләр керә:

— торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслаучы белешмәләр;

— мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документларның (шартнамә, ордер, торак урыны бирү турында карар һәм бүтән документлар) күчермәләре;

— гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукындагы торак урыннарының булуы яки булмавы турында дәүләт кадастр исәбен, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны һәм Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы белешмәләрне бирүне гамәлгә ашыручы органнар белешмәсе, ул мөрәҗәгать итүче гаиләсенең хокуктан файдалануга сәләтле һәр әгъзасыннан гариза бирелгән елга кадәрге биш ел өчен тапшырыла.

Гамәлдәге законнар шәхси финанс счеты кебек документның конкрет формасын һәм эчтәлеген билгеләми. Шуның белән бергә, барлыкка килгән хокукый практикадан чыгып, ул шул исәптән торак урынның тибы һәм характеры турында, аның торак һәм гомуми мәйданы турында белешмәләр, шулай ук әлеге торак урында яшәүче барлык затлар турында белешмәләрне үз эченә алган документтан гыйбарәт. Шулай итеп, күрсәтелгән документ торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган белешмәләр сыйфатында карала ала һәм, димәк, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу өчен юридик әһәмияткә ия булган фактларны раслау максатларында кирәкле.

Мондый хокукый җайга салу дәүләт тарафыннан торак өлкәсендә социаль ярдәм күрсәткәндә законлылык принцибын гамәлгә ашыруны да тәэмин итә, чөнки, аерым алганда, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның торак шартларын бәяләргә, торак шартларын яхшырту өчен хокукый нигезләрне, шулай ук адреслылык принцибын документлар белән расларга мөмкинлек бирә, аның нигезендә, торак шартларын яхшыртуга аларның реаль ихтыяҗларын исәпкә алып, социаль ярдәм чаралары халыкның социаль якланмаган катламнары исәбенә керә торган законда күрсәтелгән аерым категория гражданнарга күрсәтелә.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 4.1 өлеше нигезләмәләре буенча торак урынында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслаучы белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы буенча бирелүенә, ә тапшырылмаган очракта вәкаләтле орган тарафыннан мөстәкыйль рәвештә соратып алынуына игътибар итә.

Моннан күренгәнчә, 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләре гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча гражданнарны торак урынына мохтаҗлар

буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлегенә шәхси финанс счетын кертеп, вәкаләтле органның бары тик граждан тарафыннан мондый документ тапшырылмаганлыктан гына торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын раслаудан баш тарту мөмкинлеген күз алдында тотмый.

Шулай итеп, 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең нормалары үзеннән-үзе кеше һәм гражданның, шул исәптән гражданин Р.Р. Измайловның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый һәм шул рәвешле Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 54 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына каршы килми.

3.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 28.2 статьясын һәм «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 23.2 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак шартларын яхшыртуга хокуклы гражданнарны торак белән тәэмин итү аларга торак алуга субсидияләр бирү юлы белән башкарыла (1 пункт) дип билгеләнгән.

Субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 5 пункты, 8 пунктындагы икенче абзацы, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, тигезлекнең, гаделлек һәм хокукый билгеләнешнең хокукый принципларына җавап бирми, чөнки «гамәлдәге законнар» формулировкасы федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак шартларын яхшыртуга үзләренең мохтаҗлыгын субсидия алучылар тарафыннан раслау мәсьәләсе буенча нинди конкрет норматив хокукый актлар кулланылырга тиеш булуын билгеләргә мөмкинлек бирми.

«Ветераннар турында» Федераль законның 14 һәм 23.2 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләреннән күренгәнчә, федераль бюджет акчалары исәбеннән торак белән тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм чарасы торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм 2005 елның 1 гыйнварына кадәр исәпкә баскан сугыш хәрәкәтләре ветераннарына һәм инвалидларына гына кагыла.

Гражданнарны торак биналарга мохтаҗ буларак исәпкә алу, аны алып бару тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә, җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге гражданнарның күрсәтелгән органга үз яшәү урыны буенча яисә, Россия Федерациясе Хакимияте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә аларның үзара бәйләнеш турында төзелгән килешүе нигезендә, күпфункцияле үзәк аша биргән гаризалары нигезендә башкарыла (Россия Федерациясе Торак кодексының 52 статьясындагы 3 һәм 7 өлешләр).

Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән регламентланган. Шул ук вакытта Татарстан Республикасының әлеге Законында «торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны раслау тәртибе» төшенчәсенең билгеләмәсе юк. Анда гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу тәртибе (3 һәм 6 статьялар), торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торучы гражданнарны яңадан теркәү тәртибе (24 статья) һәм торак урыны бирелү турында гражданга хәбәр итү тәртибе (26 статья) билгеләнә, алар гражданнарның торак шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән билгеле юридик яктан әһәмиятле гамәлләр башкару өчен төрле хокукый нигезләрне күздә тотсалар да, шуның белән бергә җирле үзидарә органнарына бирү өчен кирәкле документларның әлеге Татарстан Республикасы Законының 6 статьясында билгеләнгән бердәм исемлеген үз эченә алган.

Мондый хокукый җайга салу, «Ветераннар турында» Федераль законның, Россия Федерациясе Торак кодексының һәм 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының югарыда күрсәтелгән нормаларының үзара бәйле нигезләмәләреннән чыгып, федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алу өчен аларга субсидияләр биргәндә гражданнар тарафыннан торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны раслау мәсьәләсенә карата гамәлдәге законнар дигәндә, аларның ачыкланган конституциячел хокукый мәгънәсен исәпкә алып, 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезләмәләрен аңларга кирәклеген күз алдында тота, алар гражданнарны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә алу өчен кирәкле документлар исемлеген регламентлый.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 5 пункты, 8 пунктындагы икенче абзацы, федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак шартларын яхшырту хокукын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларында гражданнар тарафыннан раслау тәртибе 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгәнлеген күздә тотып, алар гражданнар тарафыннан шәхси финанс счетын тапшырмаган очракта торак шартларын яхшыртуга аларның хокукын расланмаган дип танырга мөмкинлек бирми һәм үзеннән-үзе кеше һәм гражданның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яки башкача боза торган буларак карала алмыйлар һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 54 (беренче өлеш) һәм 55 статьяларына каршы килмиләр.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан гамәлгә ашырыла торган хокукый җайга салу ачыклык һәм каршылыксызлык таләпләренә җавап бирергә тиеш, ә аның гамәлдә булу механизмы конкрет норматив нигезләмәләр эчтәлегеннән яисә күзгә күренеп торган үзара бәйләнешендә булган нормалар системасы эчтәлегеннән хокук мөнәсәбәтләре субъектларына аңлаешлы булырга тиеш, дип билгели. Бу, аеруча, нормаларның социаль якланмаган гражданнар тарафыннан да, шулай ук мондый гражданнарның үзләре тарафыннан да хокук кулланучыга юнәлдерелгән очракларга кагыла. Хокукый нәтиҗәләр барлыкка килү өчен кирәкле конкрет гамәлләр кылуны күздә тотканга күрә, үзенең характеры буенча юнәлтү нормалары булган формулировкаларны куллану хокук мөнәсәбәтләре субъектларына кулланылырга тиешле норманы ачык һәм ике төрле аңлашылмый торган итеп билгеләргә мөмкинлек бирергә тиеш. Башкасы котылгысыз рәвештә хокукый җайга салуның төгәлсезлегенә һәм аңлаешсызлыгына, туры килә торган нормаларны куллануда бозып күрсәтүләргә һәм, нәтиҗәдә, хокук мөнәсәбәтләре субъектлары була торган хокукый билгесезлек ситуациясенә китерә.

Шулай итеп, Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең күрсәтелгән нормаларын әлеге Карарда ачыкланган аларның конституциячел-хокукый мәгънәсендә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану белән карала торган хокукый җайга салуны камилләштерү процессында аңа федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны раслау өчен кулланылырга тиешле законнарны төгәлләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләте кире кагылмый. Мондый җайга салу Кеше хокуклары буенча Европа Судының хокукый позициясенә туры килә, ул, хокукый билгеләнеш принцибын үтәү кирәклеген таләп итеп, үз карарларында берничә тапкыр күрсәткәнчә, закон Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турындагы конвенциядә билгеләнгән барлык законнарның җитәрлек дәрәҗәдә төгәл формалаштырылуын һәм юридик ярдәм кирәк булган очракта затка аның теге яисә бу гамәлләре нинди нәтиҗәләргә бәйле була алуын күзаллау мөмкинлеген бирүне таләп итә торган стандартка туры килергә тиеш («Игнатов (Ignatov) Россиягә каршы» эше буенча 2007 елның 24 маендагы, «Владимир Соловьев (Vladimir Solovyev) Россиягә каршы» эше буенча 2007 елның 24 маендагы карарлар).

3.3. «Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу» муниципаль хезмәте Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 27 сентябрендәге 797 номерлы карары белән расланган «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре һәм федераль башкарма хакимият органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте орган-

нары, җирле үзидарә органнары арасында үзара хезмәттәшлек турында» тәкъдим ителгән Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә «бер тәрәзә» принцибы буенча күрсәтелә ала торган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр исемлегенә кертелгән.

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясы таләпләрен исәпкә алып закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле мәгълүматка һәм документларга, һәм, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга мөмкин булганлыктан, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы документларга бүлеп, муниципаль хезмәт күрсәтү стандартында билгеләнә, ул, үз чиратында, административ регламент структурасына керә (12 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты һәм 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты).

Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пунктының шикаять белдерелә торган нигезләмәләре буенча, аларның Документлар исемлегенең I өлешендәге 8 һәм 9 пунктлары белән үзара бәйләнешендә, яшәү урыны буенча гариза бирүче белән бергә теркәлгән барлык гражданнар турында адресы, гражданнарның теркәлү датасы, документны бирү көне күрсәтелгән мәгълүматларны үзенә туплаган документ һәм торак бинаның гомуми һәм торак мәйданын, бирү датасын күрсәтеп, шәхси финанс счеты мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларга керә. Әлеге нигезләмәләр, үзенең турыдан-туры эчтәлегеннән чыгып, императив характерга ия, һәм, эш материалларыннан күренгәнчә, күрсәтелгән документларны тапшырмау торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны раслаудан мөрәҗәгать итүчегә баш тартуга китерә.

Мондый җайга салу, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел хокукый мәгънәсен исәпкә алып, 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләренә дә, шулай ук карала торган Административ регламентның 2.6 пунктына да каршы килә, аның нигезендә мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән документларны тапшыру бурычы йөкләнми.

Россия Федерациясе Конституция суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, хокукый норма эчтәлегенең билгесезлеге аның бертөрле аңлашылуына комачаулый, конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен какшата, тигезлек һәм закон өстенлеге принципларын бозуга китерергә мөмкин; шуңа күрә хокук кулланучы тарафыннан ирекле аңлатылуына китерә торган хокукый норманың билгелелеге таләбен бозу үзеннән-үзе мондый норманы Россия Федерациясе Конституциясенә туры килми дип тану өчен җитәрлек (2004 елның 6 апрелендәге 7-П номерлы, 2011 елның 20 декабрендәге 29-П номерлы, 2015 елның 2 июнендәге 12-П номерлы һ.б. карарлар).

Шулай итеп, Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пункты нормалары, аларның Документлар исемлегенең I өлешенең 8 һәм 9 пунктлары белән үзара бәйләнешендә, закон һәм суд каршында һәркемнең тигезлеге конституциячел принцибыннан килеп чыга торган хокукый норманың билгеләнеше, ачыклыгы һәм бер мәгънәдә булуы гомумхокукый критерийларына җавап бирми, шуңа күрә юридик җаваплылыкның конституциячел принципларына каршы килә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм аның нигезләмәләренә таянган Татарстан Республикасы Конституция судының хокукый позицияләрен исәпкә алып, әлеге Карардан килеп чыга торган гамәлдәге хокукый җайга салуга тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 84 статьясындагы икенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы законын яисә башка норматив хокукый актын йә аларның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану конституциячел түгел дип танылган, йә мөрәҗәгатьтә шундый нигезләмәләре күрсәтелгән актка нигезләнгән башка норматив хокукый актларның нигезләмәләрен юкка чыгаруга сәбәп була. Бу законнарның яисә башка норматив хокукый актларның нигезләмәләрен судлар, башка органнар һәм вазыйфаи затлар куллана алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6, 46, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73, 84 статьяларына, 104 статьяның беренче өлешендәге 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлеше нигезләмәләрен — гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча — гражданнарны торак урынына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен кирәкле документлар исемлегенә шәхси финанс счетын кертеп, вәкаләтле органның бары тик граждан тарафыннан мондый документ тапшырылмаганлыктан гына торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын раслаудан баш тарту мөмкинлеген күз алдында тотмаган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 5 пунктын, 8 пунктындагы икенче абзацын, федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак шартларын яхшырту хокукын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларында гражданнар тарафыннан раслау тәртибе «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгәнлеген күздә тотып, алар гражданнар тарафыннан шәхси финанс счетын тапшырмаган очракта торак шартларын яхшыртуга аларның хокукын расланмаган дип танырга мөмкинлек бирмәгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пункты нигезләмәләрен, аларның Муниципаль хезмәт, шулай ук хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлегенең (әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта) I өлешенең 8 һәм 9 пунктлары белән үзара бәйләнешендә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танырга.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетына, Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының анық нигезләмәләренә таянган хокукый позицияләрен исәпкә алып, гамәлдәге хокукый җайга салуга әлеге Карардан килеп чыга торган тиешле үзгәрешләрне кертергә.

4. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә торак урыннарга мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пунктының, әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның сигезенче абзацы белән анық үзара бәйләнешендә (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 26 декабрендәге 4641 номерлы карары кабул ителгәнчегә кадәр гамәлдә булган редакциясендә), конституциячеллеген тикшерүгә кагылышлы өлешендә әлеге эш буенча эш карауны туктатырга.

5. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты-

ның 2013 елның 14 октябрендәге 9010 нчы номерлы карары белән расланган Гражданнарга социаль наем шартнамәсе нигезендә муниципаль милектәге торак урынны бирү турында Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый актын әзерләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пунктының һәм әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 26 декабрендәге 4652 номерлы карары кабул ителгәнчегә кадәр гамәлдә булган редакциясендә) алтынчы, җиденче һәм сигезенче абзацларының конституциячеллеген тикшерүгә кагылышлы өлешендә әлеге эш буенча эш карауны туктатырга.

6. Мөрәҗәгать итүче эше буенча кабул ителгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танылган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пункты нигезләмәләренә, аларның Муниципаль хезмәт, шулай ук хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлегенең (әлеге Административ регламентка 3 нче кушымта) I өлешенең 8 һәм 9 пунктлары белән үзара бәйләнешендә, нигезләнгән хокук куллану карарлары, әгәр моның өчен башка каршылыклар булмаса, әлеге Карардагы нәтиҗәләрне исәпкә алып, билгеләнгән тәртиптә яңадан каралырга тиеш.

7. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

8. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 91-П

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки А.Н. Болдыревой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 1.1, а также абзацами четвертым и шестым пункта 2.4 Положения о порядке и условиях предоставления субсидий-льгот на оплату жилья и коммунальных услуг отдельным категориям граждан в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 24 марта 2006 года № 126**

28 ноября
2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 һәм 3 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан үзләренә беркетелгән торак урыннары булмаган затларны торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны, шулай ук ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан үзләренә беркетелгән торак урыннары булмаган затларны торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 15 июнендәге 394 номерлы карарының алтынчы абзацы һәм «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең 39 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка А.Н. Болдырева шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Әлеге шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка А.Н. Болдыревага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 37-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки О.М. Серовой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 «О дополнительных мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий»**

28 ноября
2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Э.М. Мустафиной, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки О.М. Серовой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка О.М. Серова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 «О дополнительных мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий».

Согласно оспариваемому пункту для многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий и имеющих десять и более детей, зарегистрированных и проживающих с родителями и не образовавших свои семьи, установлена ежегодная квота по обеспечению жильем в первоочередном порядке в размере 1 процента от общего числа многодетных семей, включенных в сводный список многодетных семей в Республике Татарстан на соответствующий год, и не менее чем одна семья.

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница является матерью пятерых детей, двое из которых инвалиды. В настоящее время ее семья в количестве 7 человек проживает в селе Молвино Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан в доме, жилая площадь которого составляет 35,0 кв. м.

На основании постановления Исполнительного комитета Молвинского сельского поселения Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан гражданка О.М. Серова была признана нуждающейся в улучшении жилищных условий и включена в список получателей сертификата в соответствии с Правилами выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, утвержденными постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 № 732 «О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий».

Заявительница указывает, что оспариваемая норма предусма-

тривает ежегодную квоту по обеспечению жильем в первоочередном порядке только для многодетных семей, имеющих десять и более детей. Она считает это положение несправедливым по отношению к тем многодетным семьям, которые имеют менее десятерых детей, но среди них есть дети инвалиды.

На федеральном уровне Жилищный кодекс Российской Федерации (статья 57) устанавливает, что вне очереди жилые помещения по договорам социального найма предоставляются гражданам, страдающим тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в перечне, предусмотренном пунктом 4 части 1 статьи 51 названного Кодекса. Перечень утвержден приказом Министерства здравоохранения Российской Федерации от 29 ноября 2012 года № 987н «Об утверждении перечня тяжелых форм хронических заболеваний, при которых невозможно совместное проживание граждан в одной квартире».

Однако, как указывает заявительница, обжалуемое постановление Кабинета Министров Республики Татарстан не предусматривает для многодетных семей с детьми-инвалидами, имеющими заболевания, включенные в вышеуказанный перечень, предоставление в первоочередном порядке квоты по обеспечению жильем. Она отмечает, что первоочередность предоставления квоты на жилье должна зависеть не только от количества детей у многодетной семьи, но и от нуждаемости в улучшении жилищных условий по медицинским показаниям.

На основании изложенного гражданка О.М. Серова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 «О дополнительных мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий» не соответствующим статьям 28 (части первая и вторая), 38 (части первая и третья), 54 (часть первая), 55 Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с подпунктом 24 пункта 2 статьи 26.3 Федерального закона от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации» решение вопросов социальной поддержки семей, имеющих детей (в том числе многодетных семей, одиноких родителей), относится к полномочиям органов государственной власти субъекта Российской Федерации по предметам совместного ведения, осуществляемым данными органами самостоятельно за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации (за исключением субвенций из федерального бюджета). Также данным Федеральным законом предусмотрено, что органы государственной власти субъекта Российской Федерации вправе устанавливать за счет средств бюджета субъекта Российской Федерации (за исключением финансовых средств, передаваемых из федерального бюджета бюджету субъекта Российской Федерации на осуществление целевых расходов) дополнительные меры социальной поддержки и социальной помощи для отдельных категорий граждан

вне зависимости от наличия в федеральных законах положений, устанавливающих указанное право. Финансирование названных полномочий не является обязанностью субъекта Российской Федерации, осуществляется при наличии возможности и не является основанием для выделения дополнительных средств из федерального бюджета (части третья и четвертая статьи 26.3-1).

Указом Президента Российской Федерации от 5 мая 1992 года № 431 «О мерах по социальной поддержке многодетных семей» правительствам республик в составе Российской Федерации, органам исполнительной власти краев, областей, автономных образований, городов Москва и Санкт-Петербург было поручено определить категории семей, которые относятся к многодетным и нуждаются в дополнительной социальной поддержке, с учетом национальных и культурных особенностей в социально-экономическом и демографическом развитии региона и установить для многодетных семей меры социальной поддержки (подпункты «а», «б» пункта 1).

В Республике Татарстан многодетные семьи, имеющие пять и более детей, проживающих с родителями и не образовавших свои семьи, нуждающиеся в улучшении жилищных условий, в соответствии с Указом Президента Республики Татарстан от 17 марта 2001 года № УП-216 «О дополнительных мерах по улучшению жилищных условий многодетных семей» относятся к категориям граждан, имеющих право на внеочередное получение жилых помещений.

В целях оказания дополнительной поддержки по обеспечению жильем многодетных семей Кабинет Министров Республики Татарстан принял постановление от 18 декабря 2007 года № 732 «О дополнительных мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий», которым предусмотрено предоставление многодетным семьям субсидии для приобретения жилья за счет средств бюджета Республики Татарстан.

Постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 внесены изменения в вышеуказанное постановление, а также утверждены Правила выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий. В соответствии с подпунктом «а» пункта 4 указанных Правил (в редакции постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 9 августа 2019 № 660) право на получение сертификата имеют состоящие в органах местного самоуправления на учете в качестве нуждающихся в улучшении жилищных условий многодетные семьи, имеющие пять и более детей, проживающих с родителями и не образовавших свои семьи.

В дальнейшем постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 20 декабря 2011 года № 1021 «О внесении изменений в отдельные постановления Кабинета Министров Республики Татарстан» рассматриваемое постановление было дополнено обжалуемым пунктом 4, закрепляющим дополнительные гарантии для многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных

условий и имеющих десять и более детей, зарегистрированных и проживающих с родителями и не образовавших свои семьи, в виде ежегодной квоты по обеспечению жильем в первоочередном порядке.

По своей правовой природе данная мера социальной поддержки не относится к обязательным видам социального обеспечения и, по существу, выступает в качестве дополнительного способа повышения уровня жизни многодетных семей, исходя из количества детей в них. Республика Татарстан самостоятельно определяет категории многодетных семей, имеющих право на ее получение, условия и порядок ее предоставления, принимая во внимание в том числе и возможности бюджета республики.

Тем самым обжалуемое нормативное положение не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан и само по себе не предусматривает ограничений в реализации гражданами права на улучшение жилищных условий в порядке, предусмотренном жилищным законодательством. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки не является допустимой.

Приведенные в жалобе доводы заявительницы фактически сводятся к требованию не о проверке конституционности оспариваемой нормы, а о внесении соответствующих изменений в действующее законодательство с целью предоставления квоты на жилье в первоочередном порядке многодетным семьям, не только исходя от количества детей у многодетной семьи, но и исходя из нуждаемости в улучшении жилищных условий по медицинским показаниям. Между тем разрешение данного вопроса не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», а является прерогативой законодателя Республики Татарстан.

На основании изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки О.М. Серовой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 «О дополнительных мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий», поскольку она в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является до-

пустимой, а разрешение поставленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке О.М. Серовой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 38-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка О.М. Серова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
28 ноябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка О.М. Серова шикаятен алдан өйрәнгән судья Э.М. Мостафина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка О.М. Серова «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъва белдерелә торган пункт нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм ата-аналары белән теркәлгән һәм яшәүче, үз гаиләләрен кормаган ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр өчен беренче чират тәртибендә торак белән тәэмин итү буенча тиешле елга Татарстан Республикасындагы күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлегенә кертелгән күпбалалы гаиләләрнең гомуми саныннан 1 процент һәм иң кимендә бер гаилә күләмендә еллык квота билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, биш баласының икесе инвалид булган мөрәҗәгать итүче, хәзерге вакытта 7 кешелек гаиләсе белән Яшел Үзән муниципаль районы Мулла Иле авылында торак мәйданы 35,0 кв. метр тәшкил иткән йортта яши.

Татарстан Республикасының Яшел Үзән муниципаль районы Мулла Иле авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә гражданка О.М. Серова торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган һәм «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү

кагыйдәләре нигезендә сертификат алучылар исемлегенә кертелгән.

Мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерелгән нормада торак белән беренче чиратта тәэмин итү буенча еллык квотаны ун һәм аннан артыграк баласы булган гаиләләргә генә бирү күздә тотылуын күрсәтә. Ул әлеге хәлне балалары уннан кимрәк, әмма алар арасында инвалид балалар булган гаиләләргә карата гаделсезлек дип саный.

Россия Федерациясе Торак кодексында федераль дәрәҗәдә әлеге Кодексның 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктта каралган исемлеккә кертелгән озак вакыт дәвамында дәвалауны таләп итә торган чирләрнең авыр формаларыннан интегүче гражданнарга торак урыннар социаль найм шартнамәләре буенча чираттан тыш бирелүе билгеләнә (57 статья). Исемлек Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлеген раслау турында» 2012 елның 29 ноябрендәге 987н номерлы боерыгы белән расланган.

Әмма, мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының шикаять белдерелә торган карары югарыда күрсәтелгән исемлеккә кертелгән авырулар белән интегүче инвалид балалары булган күпбалалы гаиләләр өчен торак белән тәэмин итү буенча беренче чиратта квота бирүне күздә тотмый. Ул торак өчен квота бирү беренче чиратта күпбалалы гаиләдәге балалар санына гына түгел, ә медицина күрсәткечләре буенча аның торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгына да бәйле булырга тиешлеген билгеләп үтә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка О.М. Серова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 54 (беренче өлеш), 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясындагы 2 пунктының 24 пунктчасы нигезендә балалы гаиләләргә (шул исәптән күпбалалы гаиләләргә, ялгыз ата-аналарга) социаль ярдәм мәсьәләләрен хәл итү Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының әлеге органнар тарафыннан Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла торган уртак эш башкару предметлары буенча вәкаләтләренә керә (федераль бюджеттан кергән субвенцияләрдән тыш). Әлеге Федераль законда шулай ук Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына бирелә торган финанс чараларыннан тыш)

гражданнарның аерым категорияләре өчен, федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булуына яисә булмавына карамастан, өстәмә социаль булышлык күрсәтү һәм социаль ярдәм чараларын билгеләргә хокуклы дип каралган. Әлеге вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының йөкләмәсе булып тормый, мөмкин булган очракта гамәлгә ашырыла һәм федераль бюджеттан өстәмә акчалар бүлеп бирү өчен нигез була алмый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

«Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 1992 елның 5 маендагы 431 номерлы Указы Россия Федерациясе составындагы республикалар хөкүмәтләренә, крайларның, өлкәләрнең, автоном берәмлекләрнең, Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләренең башкарма хакимияте органнарына төбәкнең социаль-икътисадый һәм демографик үсешендә милли һәм мәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып, күпбалалы гаиләләргә кергән һәм өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ гаиләләр категорияләрен һәм күпбалалы гаиләләр өчен социаль ярдәм чараларын билгеләү йөкләнгән (1 пунктның «а», «б» пунктчалары).

Татарстан Республикасында ата-аналары белән яшәүче һәм үз гаиләләрен кормаган биш һәм аннан күбрәк баласы булган, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләр «Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Президентының 2001 елның 17 мартындагы ПУ-216 номерлы Указы нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ торак урыннарын чираттан тыш алу хокукына ия булган гражданнар категориясенә керә.

Күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә өстәмә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карар кабул иткән, анда күпбалалы гаиләләргә торак алу өчен Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субсидия бирү күздә тотыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән югарыда күрсәтелгән карарга үзгәрешләр кертелгән, шулай ук торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, аларны реализацияләү кагыйдәләре расланган. Әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктындагы «а» пунктчасы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 9 августындагы 660 номерлы карары редакциясендә) нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак җирле үзидарә органнарында исәптә торучы, ата-аналары белән яшәүче һәм үз гаиләләрен кормаган биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр сертификат алу хокукына ия.

Алга таба «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 20 декабрендәге 1021 номерлы карары нигезендә карап тикшерелә торган карар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм ата-аналары белән

теркәлгән һәм яшәүче, үз гаиләләрен кормаган ун һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне беренче чиратта торак белән тәэмин итү буенча еллык квота рәвешендә өстәмә гарантияләр билгели торган 4 пункт белән тулыландырылган.

Үзенең хокукый табигате буенча әлеге социаль ярдәм чарасы социаль тәэминатның мәҗбүри төрләренә керми һәм, асылда, алардагы балалар саныннан чыгып, күпбалалы гаиләләрнең тормыш дәрәҗәсен яхшыртуның өстәмә ысулы булып тора. Татарстан Республикасы аны алу хокукына ия күпбалалы гаиләләрнең категорияләрен, аны бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән республика бюджеты мөмкинлекләрен дә исәпкә алып, мөстәкыйль билгели.

Шулай итеп, шикаять белдерелә торган норматив нигезләмәдә аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турындагы мәсьәләдә билгесезлек юк һәм үзеннән-үзе анда гражданнарның торак законнарында каралган тәртиптә торак шартларын яхшыртуга хокукын гамәлгә ашыруда чикләүләр күздә тотылмый. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясының беренче өлешенең 2 пункты нигезендә гражданканың шикаяте карала алмый.

Мөрәҗәгать итүченең шикаятьтә китерелгән дәлилләре чынлыкта дәгъва белдерелә торган норманың конституциячеллеген тикшерү турындагы таләпкә түгел, бәлки күпбалалы гаиләләргә алардагы балалар саныннан чыгып кына түгел, ә медицина күрсәткечләре буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булуларыннан да чыгып беренче чиратта торак өчен квота бирү максатларында гамәлдәге законнарга тиешле үзгәрешләр кертү турындагы таләпкә кайтып кала. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгәнчә, әлеге мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми, бәлки Татарстан Республикасында закон чыгаручының өстенлеге булып тора.

Бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясының икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка О.М. Серова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки

ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка О.М. Серовага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 38-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

3 декабря 2019 года
город Казань

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой на нарушение ее конституционных прав и свобод статьей 1 Закона Республики Татарстан от 13 июля 2013 года № 62-ЗРТ «О потребительской корзине в Республике Татарстан»**

Конституционный суд Республики Татарстан в составе заместителя Председателя Р.А. Сахиевой, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.Н. Юсипова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод статьей 1 Закона Республики Татарстан от 13 июля 2013 года № 62-ЗРТ «О потребительской корзине в Республике Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан).

Оспариваемым положением Закона Республики Татарстан установлена потребительская корзина для основных социально-демографических групп населения в Республике Татарстан до 31 декабря 2020 года включительно.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что заявительница является одиноко проживающим пенсионером с размером пенсии 8823 рубля и кроме пенсии иных дополнительных доходов не имеет. Гражданка Г.Н. Юсипова указывает, что не получает пенсию в полном объеме из-за задолженности в оплате жилищно-коммунальных услуг. При этом она нуждается в постоянном лечении и покупке лекарств, на что у нее недостаточно денежных средств, но, поскольку ее пенсия превышает прожиточный минимум, Министерство труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан отказывает ей в оказании государственной социальной помощи.

Заявительница отмечает, что в первоначальной редакции обжалуемой нормы Закона Республики Татарстан потребительская корзина для основных социально-демографических групп населения в Республике Татарстан должна была устанавливаться не реже одного раза в пять лет, то есть в следующий раз она должна была быть установлена в 2018 году. Такое ограничение в сроке, как указывает гражданка Г.Н. Юсипова, установлено Федеральным законом от 24 октября 1997 года № 134-ФЗ «О прожиточном минимуме в Российской Федерации» (далее также — Федеральный закон № 134-ФЗ), согласно которому потребительская корзина для основных социально-демографических групп населения в целом по Российской Федерации и в субъектах Российской Федерации определяется не реже одного раза в пять лет (статья 3). Однако после внесения Законом Республики Татарстан от 30 июня 2018 года № 46-ЗРТ в оспариваемую норму изменений, потребительская

корзина в Республике Татарстан установлена до 31 декабря 2020 года включительно, то есть продлена еще на 2,5 года без внесения изменений по существу, хотя заявительница полагает, что от того, что входит в потребительскую корзину, зависит размер прожиточного минимума, и если бы по истечении в 2018 году пятилетнего срока установления потребительской корзины, республиканский законодатель пересмотрел бы набор продуктов питания, а не продлевал бы этот период, то увеличилась бы и величина прожиточного минимума, а значит, ей бы полагались дополнительные социальные выплаты.

Таким образом, гражданка Г.Н. Юсипова считает, что обжалуемое положение нарушает ее конституционные права и просит Конституционный суд Республики Татарстан признать его не соответствующим статьям 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 54 (часть первая) Конституции Республики Татарстан.

1. Согласно Федеральному закону «О прожиточном минимуме в Российской Федерации» потребительская корзина для основных социально-демографических групп населения в целом по Российской Федерации и в субъектах Российской Федерации определяется не реже одного раза в пять лет, при этом в целом по Российской Федерации она устанавливается федеральным законом, а в субъектах Российской Федерации — законодательными (представительными) органами субъектов Российской Федерации с учетом природно-климатических условий, национальных традиций и местных особенностей потребления продуктов питания, непродовольственных товаров и услуг основными социально-демографическими группами населения. Методические рекомендации по определению потребительской корзины для основных социально-демографических групп населения в субъектах Российской Федерации утверждаются Правительством Российской Федерации (абзац первый пункта 1, абзац первый пункта 3, пункты 4 и 5 статьи 3). Указанные методические рекомендации утверждены постановлением Правительства Российской Федерации от 28 января 2013 года № 54.

Федеральным законом от 3 декабря 2012 года № 227-ФЗ «О потребительской корзине в целом по Российской Федерации» определена потребительская корзина в целом по Российской Федерации. В Республике Татарстан потребительская корзина установлена оспариваемым Законом Республики Татарстан.

Статьей 6 Федерального закона от 28 декабря 2017 года № 421-ФЗ «О внесении изменений в отдельные законодательные акты Российской Федерации в части повышения минимального размера оплаты труда до прожиточного минимума трудоспособного населения» в статью 4 Федерального закона от 3 декабря 2012 года № 227-ФЗ «О потребительской корзине в целом по Российской Федерации» было внесено дополнение и определено, что данный Федеральный закон действует до 31 декабря 2020 года включительно.

С учетом внесенного в вышеназванный Федеральный Закон дополнения, статьей 1 Закона Республики Татарстан от 30 июня 2018 года № 46-ЗРТ «О внесении изменения в статью 1 Закона Республики Татарстан "О потребительской корзине в Республике

Татарстан"» обжалуемая норма Закона Республики Татарстан, была изложена в новой редакции, согласно которой потребительская корзина для основных социально-демографических групп населения в Республике Татарстан также установлена до 31 декабря 2020 года включительно. При этом продукты питания и объемы потребления в потребительской корзине, утвержденной оспариваемым Законом Республики Татарстан, полностью соответствуют положениям методических рекомендаций по определению потребительской корзины для основных социально-демографических групп населения в субъектах Российской Федерации, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 28 января 2013 года № 54.

Таким образом, обжалуемая гражданкой Г.Н. Юсиповой статья 1 Закона Республики Татарстан принята в рамках федерального законодательства, сама по себе не содержит неопределенности в вопросе ее соответствия Конституции Республики Татарстан и не может рассматриваться как нарушающая конституционные права и свободы граждан, в том числе заявительницы, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» ее жалоба не является допустимой.

Формально оспаривая конституционность рассматриваемой нормы, гражданка Г.Н. Юсипова фактически ставит перед Конституционным судом Республики Татарстан вопрос о внесении целесообразных, с ее точки зрения, изменений в существующее нормативное правовое регулирование. Между тем разрешение поставленного вопроса не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73, 100 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой на нарушение ее конституционных прав и свобод статьей 1 Закона Республики Татарстан от 13 июля 2013 года № 62-ЗРТ «О потребительской корзине в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.
2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.
3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.Н. Юсиповой и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 39-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» 2013 елның 13 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
3 декабрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасары Р.Г. Сәхиева, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Н. Юсипова «Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» 2013 елның 13 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 1 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган нигезләмәсе, 2020 елның 31 декабрен кертеп, Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзинен билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, шикаять бирүче — 8823 сум күләмендә пенсия алучы, ялгыз яшәүче пенсионер һәм, пенсиядән башка, аның өстәмә керемнәре юк. Гражданка Г.Н. Юсипова, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә бурычлары булганлыктан, пенсияне тулы күләмдә ала алмавы турында күрсәтә. Шул ук вакытта ул бертуктаусыз дәваланырга һәм дарулар сатып алырга мәҗбүр, моңа аның акчасы җитми, әмма, аның пенсиясе яшәү минимумыннан артып киткәнгә күрә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы аңа дәүләттән бирелә торган социаль ярдәм күрсәтүдән баш тарта.

Мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Законының шикаять белдерелә торган нормасының башлангыч редакциясендә Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзине биш елга бер тапкыр билгеләнергә тиешлеге каралуын, ягъни аның икенче тапкыр 2018 елда билгеләнергә тиеш булганлыгын күрсәтә. Вакыт ягыннан мондый чикләү, гражданка Г.Н. Юсипова белдергәнчә, «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба

шулай ук — 134-ФЗ номерлы Федераль закон) каралган, аның нигезендә тулаем Россия Федерациясе буенча һәм Россия Федерациясе субъектларында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзине кимендә биш елга бер тапкыр билгеләнә (3 статья). Әмма дәгъва белдерелә торган нормага 2018 елның 30 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә үзгәрешләр кертелгәч, Татарстан Республикасында куллану кәрзине 2020 елның 31 декабрен кертеп билгеләнгән, ягъни асылдагы мәгънәсенә үзгәрешләр кертмичә генә тагын 2,5 елга озайтылган, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, яшәү минимумы күләме куллану кәрзиненә нәрсә керүенә бәйле, һәм куллану кәрзине билгеләнгән биш еллык чор 2018 елда тәмамлангач, республика закон чыгаручысы азык-төлек җыелмасын яңадан билгеләсә, ә бу чорны озайтмаса, яшәү минимумы күләме дә артыр иде, димәк аның үзенә өстәмә социаль түләүләр бирелергә тиеш булыр иде.

Шулай итеп, гражданка Г.Н. Юсипова шикаять белдерелә торган нигезләмә үзенең конституциячел хокукларын боза дип саный һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан аны Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» Федераль закон нигезендә тулаем Россия Федерациясе буенча һәм Россия Федерациясе субъектларында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзине кимендә биш елга бер тапкыр, шул ук вакытта тулаем Россия Федерациясе буенча ул — федераль закон нигезендә, ә Россия Федерациясе субъектларында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре тарафыннан азык-төлекне, азык-төлек булмаган товарларны һәм хезмәт күрсәтүне куллануның табигать һәм климат белән бәйле шартларын, милли традицияләрне һәм җирле үзенчәлекләрне исәпкә алып, Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару (вәкиллекле) органнары тарафыннан билгеләнә. Россия Федерациясе субъектларында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзинен билгеләүгә кагылышлы методик күрсәтмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана (3 статьяның 1 пунктындагы беренче абзац, 3 пунктындагы беренче абзац, 4 һәм 5 пунктлар). Әлеге методик күрсәтмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 28 гыйнварындагы 54 номерлы карары белән расланган.

«Тулаем Россия Федерациясе буенча куллану кәрзине турында» 2012 елның 3 декабрендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон белән тулаем Россия Федерациясе буенча куллану кәрзине билгеләнә. Татарстан Республикасында куллану кәрзине дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнгән.

«Хезмәткә түләүнең минималь күләмен хезмәткә сәләтле халыкның яшәү минимумына кадәр күтәрү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 28 декабрендәге 421-ФЗ номерлы Федераль

законның 6 статьясы белән «Тулаем Россия Федерациясе буенча куллану кәрзине турында» 2012 елның 3 декабрендәге 227-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясына өстәмә кертелгән һәм бу Федераль закон 2020 елның 31 декабрен кертеп гамәлдә була дип билгеләнгән.

Алда әйтеп кителгән Федераль законга кертелгән өстәмәне исәпкә алып, «“Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Законының шикаять белдерелә торган нормасы яңа редакциядә бәян ителгән, аның буенча Татарстан Республикасында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзине шулай ук 2020 елның 31 декабрен кертеп билгеләнгән. Шул ук вакытта Татарстан Республикасының дәгъва белдерелә торган Законы нигезендә расланган куллану кәрзиненә керүче азык-төлек продуктлары һәм куллану күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 28 гыйнварындагы 54 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларында халыкның төп социаль-демографик төркемнәре өчен куллану кәрзинен билгеләүгә кагылышлы методик күрсәтмәләр нигезләмәләренә тулысынча туры килә.

Шулай итеп, гражданка Г.Н. Юсипова тарафыннан шикаять белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы федераль законнар кысаларында кабул ителгән, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм ул гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дә, конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган буларак карала алмый, шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясының беренче өлешенең 2 пункты нигезендә аның шикаяте карала алмый.

Карап тикшерелә торган норманың конституциячеллегенә карата формаль төстә дәгъва белдереп, гражданка Г.Н. Юсипова фактта Татарстан Республикасы Конституция суды алдына гамәлдәге норматив хокукый җайга салуга, аның карашынча, максатка ярашлы булган үзгәрешләр кертү мәсьәләсен куя. Шул ук вакытта әлеге мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. «Татарстан Республикасында куллану кәрзине турында» 2013 елның 13 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.Н. Юсиповага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 39-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем четвертым пункта 1.1 Положения о порядке оказания государственной социальной помощи, в том числе на основании социального контракта, в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 сентября 2014 года № 635**

3 декабря 2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе заместителя Председателя Р.А. Сахиевой, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Р.А. Сахиевой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.Н. Юсипова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем четвертым пункта 1.1 Положения о порядке оказания государственной социальной помощи, в том числе на основании социального контракта, в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 сентября 2014 года № 635 (далее также — Положение).

Согласно оспариваемой норме государственная социальная помощь на основании социального контракта оказывается в том числе гражданам, находящимся в трудной жизненной ситуации (тяжелое заболевание, в том числе близкого родственника (супруга, родителя, ребенка), которое привело к необходимости оплаты лечения, покупке дорогостоящих лекарств или медицинских изделий, не входящих в программу государственных гарантий оказания гражданам Российской Федерации бесплатной медицинской помощи на территории Республики Татарстан; пожар, наводнение или иное стихийное бедствие, которое причинило существенный ущерб гражданину; другие ситуации, объективно нарушающие жизнедеятельность гражданина, которые он не может преодолеть самостоятельно).

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что гражданка Г.Н. Юсипова является одиноко проживающим пенсионером и получает пенсию выше прожиточного минимума, установленного в Республике Татарстан (в размере 8823 рубля), и иных дополнительных доходов не имеет. Она указывает, что на основании решения суда из-за задолженности в оплате жилищно-коммунальных услуг из ее пенсии ежемесячно взыскивают определенную сумму, в результате чего у нее остается для проживания 2912 рублей в месяц. По ее мнению, данная задолженность образовалась по вине управляющей компании, которая недопоставляла тепловую энергию в ее квартиру. Несмотря на обращения в раз-

личные государственные и муниципальные органы, ситуация не менялась, вследствие чего она была вынуждена прекратить оплату непредоставляемых услуг. По ее утверждению, после ремонта отопительной системы в 2014 году, управляющая компания решила взыскать с нее оплату за те годы, которые она не оплачивала.

Заявительница в своей жалобе отмечает, что в настоящее время находится в трудной жизненной ситуации, однако, несмотря на это, Министерством труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан ей отказано в предоставлении государственной социальной помощи, поскольку ее среднедушевой доход превышает величину прожиточного минимума, установленного в Республике Татарстан.

Кроме того, гражданка Г.Н. Юсипова указывает на неопределенность оспариваемой нормы в части ссылки на «другие ситуации, объективно нарушающие жизнедеятельность гражданина, которые он не может преодолеть самостоятельно». Она считает, что сложившаяся ситуация объективно нарушает ее жизнедеятельность, поскольку, исходя из ее содержания, определение «других ситуаций» зависит только от должностного лица, принимающего решение о предоставлении государственной социальной помощи, так как иных разъяснений по этому поводу в рассматриваемом Положении не содержится. Вследствие этого заявительница полагает, что наделение правоприменителя широкой свободой усмотрения в выборе при ее применении может привести к многочисленным необоснованным отказам в предоставлении государственной социальной помощи.

На основании вышеизложенного гражданка Г.Н. Юсипова просит признать абзац четвертый пункта 1.1 Положения о порядке оказания государственной социальной помощи, в том числе на основании социального контракта, в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 сентября 2014 года № 635 не соответствующим статьям 28 (части первая и вторая), 29 (части первая и вторая), 54 (часть первая) Конституции Республики Татарстан.

2. Правовые и организационные основы оказания государственной социальной помощи отдельным категориям граждан установлены Федеральным законом от 17 июля 1999 года № 178-ФЗ «О государственной социальной помощи» (далее также — Федеральный закон).

В соответствии с частью 1 статьи 5 вышеуказанного Федерального закона органы государственной власти субъектов Российской Федерации принимают законы и иные нормативные правовые акты, определяющие размеры, условия и порядок назначения и выплаты государственной социальной помощи, в том числе на основании социального контракта, малоимущим семьям, малоимущим одиноко проживающим гражданам, реабилитированным лицам и лицам, признанным пострадавшими от политических репрессий, и иным категориям граждан, предусмотренным данным Федеральным законом.

На основании Федерального закона, а также в целях повыше-

ния эффективности адресных форм социальной помощи лицам, оказавшимся в трудной жизненной ситуации, постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 сентября 2014 года № 635 утверждено рассматриваемое Положение, которое устанавливает механизм и условия оказания государственной социальной помощи, в том числе на основании социального контракта отдельным категориям граждан. При этом такая помощь оказывается малоимущим семьям и малоимущим одиноко проживающим гражданам, которые по не зависящим от них причинам имеют среднедушевой доход ниже величины прожиточного минимума, установленного в Республике Татарстан для соответствующих социально-демографических групп населения (пункт 1.1). Аналогичное регулирование содержится и в части первой статьи 7 Федерального закона. Следовательно, одним из основных условий для получения соответствующей помощи в силу федерального и республиканского законодательства является наличие у граждан среднедушевого дохода ниже величины прожиточного минимума, установленного в Республике Татарстан.

Кроме того, определение «других ситуаций, объективно нарушающих жизнедеятельность гражданина, которые он не может преодолеть самостоятельно» согласуется с положениями статьи 1 Федерального закона «О государственной социальной помощи», в которой установлено основное понятие «трудной жизненной ситуации», и определено как обстоятельство или обстоятельства, которые ухудшают условия жизнедеятельности гражданина и последствия которых он не может преодолеть самостоятельно. При этом данный Федеральный закон не устанавливает какие-либо критерии определения трудной жизненной ситуации, а также не наделяет субъекты Российской Федерации правом определения перечня и критериев трудной жизненной ситуации. Идентичное по своему содержанию и смыслу понятие «трудная жизненная ситуация» закреплена и в пункте 2.1.5 Национального стандарта Российской Федерации ГОСТ Р 52495-2005 «Социальное обслуживание населения. Термины и определения», утвержденного приказом Федерального агентства по техническому регулированию и метрологии от 30 декабря 2005 года № 532-ст) и в части 1 статьи 15 Федерального закона от 28 декабря 2013 года № 442 «Об основах социального обслуживания граждан в Российской Федерации», в которой закреплены четкие критерии отнесения граждан к нуждающимся в социальном обслуживании.

Таким образом, оспариваемое гражданкой Г.Н. Юсиповой Положение было принято Кабинетом Министров Республики Татарстан в рамках предоставленных федеральным законодательством субъектам Российской Федерации полномочий с учетом возможности его применения в отношении отдельных категорий граждан, в том числе на основании социального контракта, и данный нормативный правовой акт не подлежит применению в порядке, отличном от установленного Федеральным законом, и, тем самым, сам по себе не может считаться нарушающим конституционные права граждан, включая и заявительницу в указанном в жалобе

аспекте, и, следовательно, не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявительницы не является допустимой.

Из содержания жалобы следует, что она, формально оспаривая конституционность рассматриваемого абзаца четвертого пункта 1.1 Положения о порядке оказания государственной социальной помощи, в том числе на основании социального контракта, в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 сентября 2014 года № 635, по существу, настаивает на проверке правильности выбора и казуального толкования подлежащих применению правовых норм с учетом фактических обстоятельств ее конкретного дела, что к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», не относится.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой на нарушение ее конституционных прав и свобод абзацем четвертым пункта 1.1 Положения о порядке оказания государственной социальной помощи, в том числе на основании социального контракта, в Республике Татарстан, утвержденного постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 2 сентября 2014 года № 635, поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями не является допустимой, а разрешение поставленных заявительницей вопросов Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.
2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.
3. Копию настоящего Определения направить гражданке Г.Н. Юсиповой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.
4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 40-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктының дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
3 декабрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе урынбасары Р.Г. Сәхиева, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Н. Юсипова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 1.1 пунктының дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъва белдерелә торган норма буенча  социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме шул исәптән тормыш хәле авыр булган (каты авыру, шул исәптән якын туганы (хатыны (ире), атасы яки анасы, баласы) дәвалануга, Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасына керми торган кыйммәтле дарулар яки медицина әйберләре сатып алуга китергән; янгын чыгу, су басу яки гражданга шактый зур зыян салган табигый бәла-каза; гражданның тереклек эшчәнлеген ул мөстәкыйль рәвештә җиңеп чыга алмаслык итеп объектив боза торган башка хәлләр) гражданнарга күрсәтелә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.Н. Юсипова — ялгыз яшәүче пенсионер һәм ул Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан артып китә торган пенсия (8823 сум күләмендә) ала һәм аның башка өстәмә керемнәре юк. Ул күрсәткәнчә, торак-коммуналь хезмәтләргә түләүдә бурычлары булганлыктан, суд карары нигезендә ай саен аның пенсиясеннән билгеле бер сумма тотып калына, шуның нәтиҗәсендә аның яшәргә аена 2912 сум акчасы кала. Аның фикеренчә, әлеге бурыч аның фатирына җылылык энергиясен

тулысынча биреп җиткермәгән идарәче компания гаебе белән барлыкка килгән. Төрле дәүләт органнарына һәм муниципаль органнарга мөрәҗәгать итүенә карамастан, хәл үзгәрмәгән, шуның нәтиҗәсендә ул күрсәтелмәгән хезмәтләр өчен түләүне туктатырга мәҗбүр булган. Аның раславынча, 2014 елда җылылык системасын төзекләндергәннән соң, идарәче компания түләмәгән еллары өчен аннан түләтү турында карар кабул иткән.

Мөрәҗәгать итүче үзенең шикаятендә хәзерге вакытта авыр тормыш хәлендә калуы, әмма, шуңа карамастан, аның җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында урнаштырылган яшәү минимумы күләменнән артып киткәнлектән, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль ярдәм министрлыгы аңа дәүләт социаль ярдәмен күрсәтүдән баш тартуы турында белдерә.

Моннан тыш, гражданка Г.Н. Юсипова дәгъва белдерелә торган норманың «гражданның тереклек эшчәнлеген ул мөстәкыйль рәвештә җиңеп чыга алмаслык итеп объектив боза торган башка хәлләр» турында сүз барган өлешендә билгесезлек булу турында белдерә. Ул, әлеге хәл аның тормыш эшчәнлеген объектив рәвештә боза, чөнки «башка хәлләр» билгеләмәсе, аның асылыннан чыгып караганда, дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турындагы карар кабул итүче вазыйфаи заттан гына тора, чөнки тикшерелә торган Нигезләмәдә бу уңайдан башка аңлатмалар юк дип саный. Шуның нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүче хокукый күрсәтмәләрне гамәлгә ашыручыга аны кулланганда үзлегеннән киң сайлау иреге бирелү дәүләт социаль ярдәме күрсәтүдән күпсанлы нигезсез баш тартуга китерергә мөмкин дип саный.

Югарыда әйтелгәннәр нигезендә, гражданка Г.Н. Юсипова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктының дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче һәм икенче өлешләр), 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүнең хокукый һәм оештыру нигезләре «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба шулай ук — Федераль закон) билгеләнгән.

Югарыда күрсәтелгән Федераль законның 5 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары аз керемле гаиләләргә, аз керемле ялгыз яшәүче гражданнарга, реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга һәм гражданнарның әлеге Федераль законда каралган башка категорияләренә дәүләт социаль ярдәменең, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күләмнәрен, билгеләү һәм түләү шартларын һәм тәртибен ачыклый торган законнар һәм башка норматив хокукый актлар кабул итә.

Федераль закон нигезендә, шулай ук авыр тормыш хәлендә калган затларга социаль ярдәм күрсәтүнең адреслы рәвешләре нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән тикшерелә торган Нигезләмә расланган, анда гражданнарның аерым категорияләренә, дәүләт социаль ярдәме, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтүнең механизмы һәм шартлары билгеләнә. Шул ук вакытта мондый ярдәм үзләренә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында халыкның тиешле социаль-демографик төркемнәре өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз керемле гаиләләргә һәм аз керемле ялгыз яшәүче гражданнарга күрсәтелә (1.1 пункт). Шуңа тиңдәш хокукый җайга салу Федераль законның 7 статьясындагы беренче өлешендә дә бар. Димәк, федераль законнарда һәм республика законнарында каралу нигезендә, әлеге ярдәмне алу өчен төп шартларның берсе булып гражданнарның җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булуы тора.

Моннан тыш, «гражданның тереклек эшчәнлеген ул мөстәкыйль рәвештә җиңеп чыга алмаслык итеп объектив боза торган башка хәлләр» билгеләмәсе «Дәүләт социаль ярдәме турында» Федераль законның «авыр тормыш хәле» дигән төп төшенчә кертелгән һәм ул гражданның тереклек эшчәнлеге шартларын авырайта һәм ул аның яисә аларның нәтиҗәләрен мөстәкыйль рәвештә җиңеп чыга алмый торган шарт яисә шартлар буларак билгеләнгән 1 статьясы нигезләмәләренә туры килә. Шул ук вакытта әлеге Федераль закон авыр тормыш хәлен билгеләүнең нинди дә булса критерийларын кертми, шулай ук Россия Федерациясе субъектларына авыр тормыш хәлләре исемлеген һәм критерийларын билгеләү хокукын бирми. Үзенең эчтәлеге һәм мәгънәсе ягыннан тиңдәш «авыр тормыш хәле» төшенчәсе Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2005 елның 30 декабрендәге 532-ст номерлы боерыгы белән расланган «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү. Терминнар һәм билгеләмәләр» ГОСТ Р 52495-2005 Россия Федерациясе милли стандартының 2.1.5 пунктында да беркетелгән һәм «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442 номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешендә дә гражданнарны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗларга кертүнең төгәл критерийлары беркетелгән.

Шулай итеп гражданка Г.Н. Юсипова дәгъва белдергән Нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Россия Федерациясе субъектларына федераль законнарда бирелгән вәкаләтләр кысаларында, аны гражданнарның аерым категорияләренә карата, шул исәптән социаль контракт нигезендә, куллану мөмкинлеген исәпкә алып кабул ителгән, һәм әлеге норматив хокукый акт Федераль законда билгеләнгәннән аерылып тора торган тәртиптә кулланыла алмый һәм, шул рәвешчә, үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән шикаятьтә күрсәтелгән яктан мөрәҗәгать итүченең дә, конституциячел хокукларын бозу-

чы буларак санала алмый, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Шикаять эчтәлегеннән аңлашылганча, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турында нигезләмәнең 1.1 пунктының тикшерелә торган дүртенче абзацының конституциячеллегенә формаль төстә дәгъва белдереп, асылда, аның конкрет эшенә кагылышлы чынлыктагы хәлләрне исәпкә алып, кулланылырга тиешле хокукый нормаларның сайлануы һәм казуаль аңлатылуы дөреслеген тикшерүне таләп итә, бу исә Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгәнчә, Татарстан Республикасы Конституция суды компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәнең 1.1 пунктының дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.Н. Юсипова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул билгеләнгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.
2. Әлеге шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.
3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.Н. Юсиповага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.
4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 40-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданина А.В. Орлова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 «О дополнительных мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий» (в редакции постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 20 декабря 2011 года № 1021)**

12 декабря
2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданина А.В. Орлова,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратился гражданин А.В. Орлов с жалобой на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 «О дополнительных мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий» (в редакции постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 20 декабря 2011 года № 1021) (далее также — постановление Кабинета Министров Республики Татарстан).

Согласно пункту 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан для многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий и имеющих десять и более детей, зарегистрированных и проживающих с родителями и не образовавших свои семьи, установлена ежегодная квота по обеспечению жильем в первоочередном порядке в размере 1 процента от общего числа многодетных семей, включенных в сводный список многодетных семей в Республике Татарстан на соответствующий год, и не менее чем одна семья.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что заявитель с супругой и 10 детьми совместно проживали в квартире на основании договора найма. Однако в этой квартире по месту постоянного проживания зарегистрирован только сам гражданин А.В. Орлов, поскольку собственник жилья не дал согласие на регистрацию его супруги и детей. Супруга и дети зарегистрированы в другой квартире, принадлежащей на праве собственности родителям его супруги, но там не проживают.

Как указывает в своей жалобе заявитель, несмотря на то, что они с супругой и детьми с 2013 года состоят на учете в качестве нуждающихся в улучшении жилищных условий, им отказывают во включении в Сводный список многодетных семей в Республике Татарстан на очередной год и, соответственно, в Список граждан — получателей жилищных сертификатов в планируемом году

по причине отсутствия совместной регистрации. По его мнению, предусмотренное оспариваемой нормой формальное требование о совместной регистрации приводит к тому, что не имеющая такой регистрации многодетная семья, хотя и проживает совместно, не может реализовать свое право на ежегодную квоту по обеспечению жильем в первоочередном порядке.

Гражданин А.В. Орлов считает, что такое правовое регулирование нарушает его право на социальное обеспечение, гарантированное Конституцией Республики Татарстан, и конституционные принципы равенства и справедливости. В подтверждение своей позиции он ссылается на постановление Конституционного суда Республики Татарстан от 30 мая 2019 года № 83-П, полагая, что изложенные в нем правовые позиции могут быть распространены и на рассматриваемое положение.

На основании изложенного гражданин А.В. Орлов просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 «О дополнительных мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий» в той части, в какой он устанавливает, что право на ежегодную квоту по обеспечению жильем в первоочередном порядке имеют только те многодетные семьи, имеющие десять и более детей, проживающих с родителями и не образовавших свои семьи, члены которой зарегистрированы в одном жилом помещении, не соответствующими статьям 13, 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 38 (части первая и третья), 54 (часть первая), 55 Конституции Республики Татарстан.

2. Вопрос, касающийся нормативного требования совместной регистрации всех членов многодетной семьи по одному месту жительства для получения на безвозмездной основе субсидии для приобретения жилья за счет средств бюджета Республики Татарстан, уже был предметом рассмотрения Конституционного суда Республики Татарстан. В своем постановлении от 30 мая 2019 года № 83-П Конституционный суд Республики Татарстан пришел к выводу, что регулирование, устанавливающее наличие регистрации всех членов многодетной семьи по одному месту жительства в качестве обязательного условия для получения жилищного сертификата, фактически представляет собой формально-юридическое препятствие для реализации ими права на улучшение жилищных условий. Отсутствие регистрации всех членов многодетной семьи по одному месту жительства не исключает возможность установления их места жительства на основе других данных, не обязательно исходящих от органов регистрационного учета, и, во всяком случае, не может ставить под сомнение право многодетной семьи на дополнительную поддержку со стороны государства. Предоставление сертификатов тем многодетным семьям, члены которых имеют совместную регистрацию по одному месту жительства, при невозможности получения аналогичных социальных гарантий семьями, относящимися к той же категории, но не имеющими совместной регистрации, влечет неоправданную дифференциацию, которая, в свою очередь, приводит к снижению

уровня их социальной защиты. Такое правовое регулирование в нарушение конституционного принципа равенства приводит не только к необоснованным различиям в объеме социальных прав многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, но и искажает само существо рассматриваемого права, что не согласуется с конституционно значимыми целями возможных ограничений прав и свобод человека и гражданина.

В этой связи Конституционный суд Республики Татарстан признал подпункт «а» пункта 4 Правил выдачи, реализации сертификатов для обеспечения жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий, утвержденных постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 16 мая 2008 года № 326 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 "О мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий"» (далее также — Правила), не соответствующими Конституции Республики Татарстан в той мере, в какой его положения ставят право на получение сертификата многодетными семьями, нуждающимися в улучшении жилищных условий, в зависимость от наличия совместной регистрации всех членов семьи по одному месту жительства.

Во исполнение указанного постановления Конституционного суда Республики Татарстан Кабинет Министров Республики Татарстан постановлением от 9 августа 2019 года № 660 внес соответствующие изменения в подпункт «а» пункта 4 рассмотренных Правил.

Обжалуемые гражданином А.В. Орловым правовые положения пункта 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан в той части, в которой они обжалуются заявителем, аналогичны по своему содержанию и смыслу положениям рассмотренного Конституционным судом Республики Татарстан подпункта «а» пункта 4 Правил, признанным Конституционным судом Республики Татарстан не соответствующими Конституции Республики Татарстан.

Согласно пункту 3 части первой статьи 46 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан принимает решение об отказе в принятии обращения к рассмотрению в случае, если по предмету обращения ранее им было вынесено постановление, сохраняющее свою силу.

Поскольку оспариваемая заявителем норма содержит такие же положения, какие уже были предметом обращения в Конституционный суд Республики Татарстан, и по ним вынесено постановление, сохраняющее свою силу, жалоба гражданина А.В. Орлова не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», а потому не может быть принята Конституционным судом Республики Татарстан к рассмотрению.

Вместе с тем частью четвертой статьи 68 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» установлено, что в случае, если при рассмотрении дела Конституционным судом Республики Татарстан выявлены нормативные

правовые акты или их отдельные положения, воспроизводящие нормы, признанные его решением не соответствующими Конституции Республики Татарстан либо противоречащими установленному в его решении конституционно-правовому смыслу рассмотренных норм, Конституционный суд Республики Татарстан вправе определить срок и порядок их приведения в соответствие с Конституцией Республики Татарстан.

В этой связи Кабинету Министров Республики Татарстан надлежит — исходя из требований Конституции Республики Татарстан и с учетом основанных на ее положениях правовых позиций Конституционного суда Республики Татарстан — внести в действующее правовое регулирование надлежащие изменения, вытекающие из постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 30 мая 2019 года № 83-П и настоящего определения.

Исходя из изложенного и руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 3 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, частью 4 статьи 68, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданина А.В. Орлова на нарушение его конституционных прав и свобод пунктом 4 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 18 декабря 2007 года № 732 «О дополнительных мерах по обеспечению жильем многодетных семей, нуждающихся в улучшении жилищных условий», поскольку обжалуемая норма содержит такие же положения, какие уже были предметом рассмотрения в Конституционном суде Республики Татарстан и по которым вынесено постановление, сохраняющее свою силу.
2. Кабинету Министров Республики Татарстан надлежит — исходя из требований Конституции Республики Татарстан и с учетом основанных на ее положениях правовых позиций Конституционного суда Республики Татарстан — внести в действующее правовое регулирование надлежащие изменения, вытекающие из постановления Конституционного суда Республики Татарстан от 30 мая 2019 года № 83-П и настоящего определения.
3. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.
4. Копию настоящего Определения направить гражданину А.В. Орлову и в Кабинет Министров Республики Татарстан.
5. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан» и на «Официальном портале правовой информации Республики Татарстан» (PRAVO.TATARSTAN.RU).

№ 41-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 20 декабрендәге 1021 номерлы карары редакциясендә) 4 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.В. Орлов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2019 ел
12 декабрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин А.В. Орлов шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин А.В. Орлов «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 20 декабрендәге 1021 номерлы карары редакциясендә) (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) 4 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 4 пункты нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ һәм ата-аналары белән теркәлгән һәм яшәүче, үз гаиләләрен кормаган ун һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр өчен беренче чират тәртибендә торак белән тәэмин итү буенча тиешле елга Татарстан Республикасындагы күпбалалы гаиләләрнең җыелма исемлегенә кертелгән күпбалалы гаиләләрнең гомуми саныннан 1 процент һәм иң кимендә бер гаилә күләмендә еллык квота билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүче хатыны һәм 10 баласы белән бергәләп найм килешүе нигезендә фатирда яшәгән. Әмма бу фатирда даими яшәү урыны буенча гражданин А.В. Орлов үзе генә теркәлгән, чөнки торак милекчесе аның хатыны һәм балаларын теркәүгә ризалык бирмәгән. Аның хатыны һәм балалары хатыны ата-анасының милек хокукында булган башка фатирда теркәлгәннәр, әмма анда яшәмиләр.

Мөрәҗәгать итүче үзенең шикаятендә күрсәткәнчә, 2013 елдан бирле хатыны һәм балалары белән торак шартларын яхшыр-

туга мохтаҗлар буларак исәптә торуларына карамастан, аларны Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең чираттагы елга җыелма исемлегенә кертүдән баш тарталар һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, планлаштырыла торган елда торак сертификатларын алачак гражданнар исемлегенә, бергәләп теркәлү булмау сәбәпле, кертелмиләр. Аның фикеренчә, дәгъва белдерелә торган нормада каралган бергәләп теркәлү турындагы формаль таләп бу рәвешле теркәлмәгән күпбалалы гаиләнең, бергә яшәсә дә, торак белән тәэмин итү буенча еллык квотага үзенең хокукын беренче чиратта гамәлгә ашыра алмавына китерә.

Гражданин А.В. Орлов мондый хокукый җайга салу аның Татарстан Республикасы Конституциясендә гарантияләнгән социаль тәэминатка хокукын һәм конституциячел тигезлек һәм гаделлек принципларын боза дип саный. Үзенең позициясен раслар өчен ул Татарстан Республикасы Конституция судының 2019 елның 30 маендагы 83-П номерлы карарын мисалга китерә, анда бәян ителгән хокукый позицияләрне карап тикшерелә торган нигезләмәгә карата да кулланырга мөмкин дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.В. Орлов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пунктын, аның ата-аналары белән теркәлгән һәм яшәүче, үз гаиләсен кормаган ун һәм аннан да күбрәк баласы булган, әгъзалары бер үк торак урында теркәлгән күпбалалы гаиләләр генә торак белән тәэмин итү буенча еллык квотага беренче чиратта хокуклы була дип билгеләнгән өлешендә, Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 54 (беренче өлеш), 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Торак сатып алырга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән кире кайтарылмый торган субсидия алу өчен күпбалалы гаиләнең барлык әгъзалары бер үк яшәү урынында бергә теркәлгән булу норматив таләбенә кагылышлы мәсьәлә Татарстан Республикасы Конституция судында карап тикшерү предметы булган иде инде. 2019 елның 30 маендагы 83-П номерлы карарында Татарстан Республикасы Конституция суды торак сертификатын алу өчен мәҗбүри шарт буларак күпбалалы гаиләнең барлык әгъзалары бер үк яшәү урынында бергә теркәлгән булырга тиешлеген билгели торган җайга салу фактта алар тарафыннан торак шартларын яхшырту хокукын гамәлгә ашыру өчен формаль-юридик киртә булып тора дигән нәтиҗәгә килде. Күпбалалы гаиләнең барлык әгъзаларының бер үк яшәү урынында теркәлмәгән булуы теркәү исәбенә кую органнарыннан алынуы мәҗбүри булмаган башка мәгълүматлар нигезендә аларның яшәү урынын билгеләү мөмкинлеген юкка чыгармый һәм, һәрхәлдә, күпбалалы гаиләнең дәүләттән өстәмә ярдәм алу хокукын шик астына куя алмый. Әгъзалары бер үк яшәү урынында бергә теркәлгән күпбалалы гаиләләргә сертификатлар бирү, шул ук

категориягә керүче, әмма бергә теркәлмәгән гаиләләрнең шундый ук социаль гарантияләрне алу мөмкинлеге булмаганда, акланмаган бүленү китереп чыгара, ә бу, үз чиратында, аларның социаль яклануы дәрәҗәсенең кимүенә китерә. Конституциячел тигезлек принцибын боза торган мондый хокукый җайга салу торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрнең социаль хокуклары күләмендә нигезсез аерымлыкларга гына түгел, бәлки карап тикшерелә торган хокукның асылы бозылуга китерә, ә бу исә кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен мөмкин булган чикләүләрнең конституциячел әһәмиятле максатларына туры килми.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды «“Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү, реализацияләү кагыйдәләренең (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) 4 пунктындагы «а» пунктчасын, аның нигезләмәләре торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрнең сертификат алу хокукын гаиләнең барлык әгъзаларының бер үк яшәү урынында бергәләп теркәлгән булуына бәйлелеккә куйган дәрәҗәдә, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип таныды.

Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карап тикшерелгән Кагыйдәләрнең 4 пунктындагы «а» пунктчасына 2019 елның 9 августындагы 660 номерлы карары белән тиешле үзгәрешләр керткән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 4 пунктындагы гражданин А.В. Орлов шикаять белдерә торган хокукый нигезләмәләр үзләренең эчтәлеге һәм мәгънәсе ягыннан мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган өлешендә Кагыйдәләрнең 4 пунктындагы Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карап тикшерелгән «а» пунктчасындагы Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танылган нигезләмәләргә тәңгәл.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, әгәр аның тарафыннан мөрәҗәгать предметы буенча әле дә үз көчен югалтмаган карар элегрәк инде чыгарылган булса, мөрәҗәгатьне карап тикшерүгә алудан баш тарту турында карар кабул итә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган нормада алдарак инде Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү предметы булып торган нигезләмәләр булганлыктан һәм алар буенча әле дә үз көчен югалтмаган карар чыгарылган-

лыктан, гражданин А.В. Орлов шикаяте «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы таләпләренә җавап бирми, шуңа күрә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга алына алмый.

Шуның белән бергә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы дүртенче өлешендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан эшне караганда, аның карары белән Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми яисә аның карарында карап тикшерелгән нормаларның конституциячел-хокукый мәгънәсенә каршы килә дип танылган нормалары булган норматив хокукый актлар яисә аерым нигезләмәләр табылган очракта, Татарстан Республикасы Конституция судының аларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерү срогын һәм тәртибен билгеләргә хокуклы булуы әйтелгән.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының аның нигезләмәләренә таянган хокукый позицияләрен исәпкә алып — гамәлдәге хокукый җайга салуга Татарстан Республикасы Конституция судының 2019 елның 30 маендагы 83-П номерлы карарыннан һәм әлеге билгеләмәдән килеп чыга торган тиешле үзгәрешләрне кертергә тиеш.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 3 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 68 статьясындагы 4 өлешенә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин А.В. Орлов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять белдерелә торган нормага Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан инде карап тикшерү предметы булып торган һәм алар буенча әле дә үз көчен югалтмаган карар чыгарылган шундый ук нигезләмәләр керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының аның нигезләмәләренә таянган хокукый позицияләрен исәпкә алып — гамәлдәге хокукый җайга салуга Татарстан Республикасы Конституция судының 2019 елның 30 маендагы 83-П номерлы карарыннан һәм әлеге билгеләмәдән килеп чыга торган тиешле үзгәрешләрне кертергә тиеш.

3. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

4. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин А.В. Орловка һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

5. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

№ 41-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 8 постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 20 декабря 2018 года № 6433 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани»**

27 декабря 2019 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Ф.Р. Волковой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Г.Н. Юсиповой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Г.Н. Юсипова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод пунктом 8 постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 20 декабря 2018 года № 6433 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани» (далее также — постановление Исполнительного комитета муниципального образования города Казани).

Согласно пункту 8 постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани размер платы за содержание жилого помещения в многоквартирном доме рассчитывается и изменяется в зависимости от состава предоставляемых услуг и конструктивных особенностей многоквартирного дома.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что гражданка Г.Н. Юсипова является собственником жилого помещения в многоквартирном доме, размер платы за содержание жилых помещений в котором установлен постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани. Заявительница отмечает, что она проживает в доме, построенном в 1960 году, он находится в неудовлетворительном техническом состоянии, физически изношен, в связи с чем ей приходится платить больше чем требуется за содержание тех объектов, которые, возможно, уже не соответствуют своему назначению. По ее мнению, оспариваемая норма не содержит всех критериев, установленных пунктом 11 Правил содержания общего имущества в многоквартирном доме, утвержденных постановлением Правительства Российской Федерации от 13 августа 2006 года № 491 (далее также — Правила), согласно которому услуги и работы по содержанию общего имущества зависят от состава, конструктивных особенностей, степени физического износа и технического состояния общего имущества, а также от геодезических и природно-климатических условий расположения многоквартирного дома. Из содержания обжалуемого положения, как указывает гражданка Г.Н. Юсипо-

ва, неясно, что понимается под конструктивными особенностями многоквартирного дома и как они влияют на расчет и изменение платы за содержание жилого помещения.

Усматривая неопределенность в вопросе о том, кем рассчитывается размер платы с учетом конструктивных особенностей жилого дома, и как они влияют на увеличение размера платы за содержание жилого помещения, заявительница полагает, что в связи с этим управляющая компания может изменять размер платы за содержание жилого помещения, который уже установлен органами местного самоуправления.

На основании изложенного, гражданка Г.Н. Юсипова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать пункт 8 постановления Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 20 декабря 2018 года № 6433 «О размере платы за пользование жилым помещением (платы за наем), за содержание жилых помещений в жилищном фонде г. Казани» не соответствующим статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49 Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с взаимосвязанными положениями частей 1 и 2 статьи 39 Жилищного кодекса Российской Федерации, а также пункта 28 Правил, собственники помещений в многоквартирном доме обязаны нести бремя расходов на содержание общего имущества соразмерно своим долям в праве общей собственности на это имущество путем внесения платы за содержание и ремонт жилого помещения в многоквартирном доме. Указанная плата в силу пункта 1 части 2 статьи 154 и части 1 статьи 156 Жилищного кодекса Российской Федерации входит в структуру платы за жилое помещение и коммунальные услуги для собственника помещения в многоквартирном доме и устанавливается в размере, обеспечивающем содержание общего имущества в многоквартирном доме в соответствии с требованиями законодательства.

